Фарсель Зыятдинов

# Читекле Кәтүк

Балалар өчен хикәяләр



КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2010

УДК 821.512.145-3-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4
З82

Рәссамы *Ания Хисмәтова*

**Зыятдинов, Ф.С.**

З82 Читекле Кәтүк : балалар өчен хикәяләр / Фарсель Зыятдинов.— Казан : Татар. кит. нәшр., 2010.— 72 б.
ISBN 978-5-298-01718-3

Китапта язучы Фарсель Зыятдиновның балалар өчен хикәяләре тәкъдим ителә.

УДК 821.512.145-3-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-01718-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Зыятдинов Ф.С., 2010



# Һәркемнең үз һөнәре



## Бип - бип

Көне буе чирәм өстендә чемченеп тамагын туйдыргач, Каз бәбкәсе әйләнә-тирәдәге әйберләр, бөҗәкләр, кошкортлар белән танышуын дәвам итте. Бәбкә өчен әле җирдә бар нәрсә яңа иде. Тукта-тукта, менә бу үлән нигә селкенеп куйды әле?

— Бип-бип, кызык бик-бик! — диде Бәбкә, сәер генә.

Гаҗәп шул, җил дә юк, ә үлән селкенә... Нидән булыр икән бу?!

Каз бәбкәсе, сак кына басып, бака үләне янына якынлашты. Көтмәгәндә үлән тагын да көчлерәк селкенеп куйды. Бәбкәнең йөрәге жу итеп китте. Кирегә йөгереп качмакчы иде, әмма әнкәсенең «кыйгак-кыйгак» дип дәрт биреп торуын ишеткәч, алга тәвәккәлләде. Нәкъ шул чакны ул бака үләне төбендәге нәзек билле бик кечкенә бер Кырмысканы күреп алды.

— Бип-бип, кемнән курыкканмын бит, оят бик-бик, — диде Бәбкә һәм, гарьлегеннән үчләнеп, Кырмысканы үртәргә кереште: — Бип-бип, кечкенә син бик-бик. Бипбип, би-би, бәби!

Мондый хурлауга сабыр Кырмысканың түземлеге җитмәде:

— Үзең син бә-би! — диде ул кисәк кенә һәм, Каз бәбкәсеннән дә озынрак саламны сөйрәп, үз юлына китеп барды.

Кырмысканың куәтен күреп, Бәбкә хәйран калды, хәтта ул бәбкәләр теленнән язды һәм, энисенә охшатыбрак:

— Кый-гак, — дип куйды.



## Карга белән Шөпшә

Җәй көзгә авышып, кырлардагы чәчәкләр инде коела башлагач, Шөпшә, ашарына баллы ризык эзләп, авыл якларына таба юл тотты. Шулчак аның борынына әллә каян бал исе килеп бәрелгәндәй булды. Караса, юл читендә шар кебек бернәрсә ята. Бал исе шуннан килә түгелме соң? Тукта, татып карыйм әле, дип уйлап алды Шөпшә тиз генә.

Тик нәрсә соң бу, ашарга ярыймы икән үзен? Шөпшә шулай икеләнеп торган арада, шар янына Карга килеп кунды.

— Кар! — диде ул һәм яшел шарны чукып та алды.

— Быз-з! Мин таптым аны, тимә, минеке ул! — диде Шөпшә һәм, ачуы чыгып, Карга өстенә уктай атылды. Әмма борыны Карга чукыган урындагы баллы суга тиеп киткәч, ачуы басылды.

Шөпшәне күргәч, «кар-р» диде Карга һәм икенче урыннан чукый башлады.

— Быз-з, — диде Шөпшә һәм яңа чукылган урынга килеп кунды да тәмле суны йотлыгып суырырга тотынды. Нәрсә ашыйлар, үзләре дә белмиләр. Тирә-якта аларның шат авазлары гына яңгырап тора:

— Кар! Быз! Кар! Быз-з! Кар-быз!



## Сыерчыклар һәм Чык-Чырыйк

Апрель иртәсе иде. Ишегалдына җыелган кар суларында кояш уйный, өй кыекларына, тәрәзә капкачларына тезелешеп, чыпчыклар чыркылдаша. Кинәт өй артындагы тупылга бер төркем сыерчык килеп кунды. Алар, үзара нидер серләшә-серләшә, аз гына хәл алды. Аннары, дәррәү күтәрелеп, юлларын дәвам итте. Тупылда бары ике сыерчык калды. Алар никтер моңсу, ямансу иде...

Тупыл ботагында моңаеп утырган сыерчыкларны чыпчык малае Чык-Чырыйк шунда ук танып алды һәм чыркылдарга кереште. Әмма сыерчыклар аңа игътибар итмәде. Кайгылары зур иде шул аларның. Чык-Чырыйк исә сыерчыклар янындагы ботакка килеп кунды да аларны үчекли бирде:

— Килмешәкләр килгән, килмешәкләр, чырыйк-чырыйк... Салкын көннәр җитсә, качалар, көн җылынса, кайталар, чырыйк-чырыйк. Ә без кышын да, җәен дә биредә. Кешеләр белән. Кыш көннәрендә бездән дә матур сайраучы кош юк бу тирәдә... Шуңа күрә безне кешеләр хөрмәт итә. Ә сезнең оягызны да алганнар... Хурланмыйча ничек кайттыгыз сез, чык-чырыйк?..

Сыерчыклар уйга калды. Усал телле бу чыпчык малаеның сүзләрендә әллә чынлап та хаклык бармы? Әллә кешеләр безгә чынлап та үпкәләгәнме? Узган ел нәкъ шушы агачта аларның оялары бар иде бит. Шунда нәниләрен үстергән иделәр...

— Тукта әле, Чык-Чырыйк, — диде Сыерчык. — Ни эшләп без килмешәк булыйк ди? Икебез дә шушы авылда туып үстек ич... Безгә моннан да якынрак авыл, моннан да якынрак бакча юк. Шуңа күрә чиксез киң диңгезләрне, ап-ак түбәле тауларны, сусыз чүлләрне кичеп, меңнәрчә чакрым юл үтеп һәр язны туган җиребезгә кайтабыз... Ә кемнең күбрәк файда китерүенә килгәндә, моны кешеләр үзләре генә белә. Дөрес, безнең ояны быел алу-





ын алганнар. Әмма монда да сәбәбен кешеләр генә белә. Әнә безне яхшы белүче Айдар өеннән чыгып килә. Ул кемне якынрак күрә икән, синеме, безнеме? Әйдә, аннан сорыйк.

Сыерчык канатларын җилпеп алды да Айдарга текәлеп сайрарга кереште. Ә Айдар исә:

— Сы-ер-чык-лар килгән! Сыерчыклар! — дип кычкыра-кычкыра, өенә кереп китте.

Бу хәлгә чыпчык малае Чык-Чырыйк та, сыерчыклар да аптырап калдылар. Айдар нигә сыерчыкларга бер җавап та, сәлам дә бирмәде? Чынлап та, чыпчык малаеның сүзләре хак микәнни?

Шулчак Айдар үзенең энесе Айвазны иyяртеп әйләнеп тә чыкты. Кулында өр-яңа сыерчык оясы иде. Энесе белән икәүләп алар аны иске оя урынына элеп куйдылар.

Бу хәлне күргән усал телле чыпчык малае Чык-Чырыйк тавыш-тынсыз гына тәрәзә капкачы артына кереп посты һәм тәмам телсез калды...



## Тапкыр Гөләп

Җил уйнады һәм улады, дулады, ыжгырды, ялгыз агач куакларын үртәп, сыбызгы булып сызгырды, агач ботакларын сындырды. Тау битендәге ялгыз агачлар явыз Җилдән бигрәк тә нык газап чикте. Алар, бу кимсетүләргә түзә алмыйча, Кояштан ярдәм сорадылар. Ләкин юкка гына, чөнки Кояш ул чакта әле Җилне яклый иде.

— Ә, шулаймы, — диде ул, — түзегез инде алайса...

Җил бер тирән чокырга кереп посты да каш астыннан гына җир өстен күзәтә башлады: янәсе, теге агачлар нишли икән?

Ачулы һәм көчле Кояш җиргә ут чәчәргә тотынды. Агачларның яфраклары сәлперәеп төштеләр, чәчәкләре коелды, еларга яшьләре дә калмады, кибеп бетте.

Хәлдән тайган агачлар еракта күренеп торган Иделгә кычкырдылар, ярдәм сорадылар. Шәфкатьле Идел, агачларның хәлен аңлап һәм аларга ярдәм итмәкче булып, үзенең парларын агачлар ягына җибәрде. Тик ул парлар хәлсез агачларга ярдәм итә алмады. Иңкүлектә качып яткан Җил, бу хәлне күрү белән, Идел-



не телгәләп ташларга җитеп, агачларның ботакларын айкап, су парларын куып алып китте. Идел өстендә тау-тау дулкыннар күтәрелде, яр читендәге зур-зур ташлар су төбенә тәгәрәде. Идел суы ярларыннан бәреп чыкты. Котырынган җил агачларны баш ияргә мәҗбүр итте.

...Агачларны кыйный-кыйный Җилнең дә хәле беткән иде, һәм ул йокыга талды. Җил тынгач, Карт Имән тамак кырды да:

— Җил үзе генә әллә кая китә алмас иде, аны Кояш яклый, — диде агачларга.

— Җил белән Кояшта инде бөтен хөкем, ә без нәрсә эшли алабыз, — диде Усак, борын астыннан гына мышкылдап.

— Бездә дә көч җитәрлек, — диде Чаган. — Ә менә шул көчне ничегрәк файдаланырга? Менә монысы сорау...

— Әйдәгез, — диде Гөләп, — тоташ стена булып үсик. Кояш Җилне якласа, Идел безнең яклы бит.

Агачлар Гөләпнең сүзен хуп күрделәр. Алсу таң сызылып килгән тыныч бер иртәдә агачлардан тоташ стена барлыкка килде.

— Әй, тор, — диде Кояш, йоклап яткан Җилне күреп,— юньлелеккә йокламыйсыңдыр син, Җил туган...

Җил киерелде, сузылды да агачлар өстенә ыргылды, ләкин тоташ стенага бәрелеп, күзләрен бер ачты, бер йомды. Улады, дулады, ыжгырды — бернәрсә дә барып чыкмады. Җил үз хәлен аңлап алды да агачларга буйсынырга булды.

Шул көннән башлап Җил дә, Кояш та, Идел дә яшеллеккә ярдәм итәләр икән...



# Һәркемнең үз һөнәре...

Июнь урталары иде. Айдарның әнисе ял алып ерак туганнарына кунакка китте. Киткәндә бакчаны исән-сау килеш Айдарга тапшырды:

— Кара аны, улым, бөҗәкләрдән яхшылап саклый күр бакчабызны. Хәзер инде синең тәҗрибәң зур, мин сиңа ышанам, — диде.

Шулай бер көн, бер төн үтте. Иртәгесен Айдар бакчадагы җимеш агачларын карап йөри иде, алмагачта берничә йонлач корт күреп алды. Мондый «җанвар»ны беренче күрүе иде. Карарга ук куркыныч йонлач, тырпаеп тора...

Нәрсә эшләргә, кемнән ярдәм сорарга? Бакчада песи Акбаштан, көчек Акбайдан һәм куян Куркак белән тавык Кунактан башка җан иясе юк иде. «Бәлкем, Акбаш дуска ялынып карарга кирәктер? — дип уйлады Айдар.— Үзе ботактан ботакка шәп сикерә. Йонлач бүлемдекләрне хәзер тотып бетерер...»

Акбашны ул алмагач төбенә алып килде дә ни эшләр икән дип күзәтә башлады. Шул вакыт бер йонлач яфрак кимереп яткан җиреннән ничектер ычкынып китте дә лып итеп Акбашның башына килеп төште. Песи, куркуыннан кая керер тишек тапмыйча, Куркаклар янына сыптырды.

«Бәлки, Акбай дуска ялынып карагадыр? Этнең кешеләргә ярдәме зур булгач, ул башкармас эш булмас»,— дип уйлады Айдар. Акбай исә, йонлачларны күргәч, башта аптырап калды, аннары, сырт йоннарын кабартып, алгы тәпиләре белән йонлачка үрелде. Йонлач бүлемдек шунда ук боҗра кебек йомарланды да җиргә сикерде. Акбай исә бер адым артка чигенде, тәпиләрен башкача йонлачка сузарга батырчылык итмәде.

— Нәрсә торасың, тот диләр бит сиңа йонлачны, — диде Айдар, ачуы чыгып. — Күрәсең бит, алмагачның яфракларын ничек телгәлиләр. Сиңа алма кирәкми! Әзер аш, сөяк кенә булсын сиңа!..

Ачуы чыгып, Айдар Акбайны читкә үк этеп җибәрде. Тегесе исә, чиный-чиный, Акбаш янына китеп барды.

Хәзер нәрсә эшләргә инде? Әнием кайтса, ни күзем белән күренермен? Куян Куркакка ялынып карасам?.. Булмас аннан да, эт булып эт тә курыккач, Куркакны уйлыйсы да юк. Әһә! Әгәр дә тавыгыбыз Кунакка әйтеп карасам?

Айдарның уен сизгәндәй, Кунак кытаклый ук башлады. Аның әле генә йомырка салып чыгуы икән. Айдар тавык янына килде.

— Кунак, ә Кунак, булыш әле миңа... Әнә йонлачлар алмагачны бетерә. Көнләп түгел, сәгатьләп үрчиләр...

Кунакның исе дә китми, җырлый-җырлый җирдә чүпләнә бирә. Тоттырмый да, тыңламый да...

Бик озак азапланды Айдар Кунак белән. Аны култык астына кыстырып килгәндә, алмагачта бер генә йонлач та калмаган иде.

Кая китәрләр икән соң болар? Айдар аптырап торды-торды да Кунакны җибәрде. Кунак исә кишер яфрагы арасына төшеп яшеренгән бер йонлачны кабып йотты да җырын дәвам итте.

Кем чүпләп бетергән бу йонлачларны? Әллә ашап туйганнар да китеп барганнармы? Айдар агачка ныграк текәлеп караган иде, иң өске ботакта томшыгын чистартып утырган бер сыерчыкны күреп алды.

— Менә белдеңме инде, Айдар, йонлачларны кем чүпләгәнне? — диде ул үз-үзенә.

Һәркемнең үз һөнәре шул!



## Рәхмәт, кошкайлар!



Җилсез, кояшлы көн иде. Әнкәсе бакчадагы алма агачы төбенә җәймә җәйде дә, Илгизәрнең ялгызын калдырып, өйгә кереп китте... Илгизәр исә үрмәләп җәймә читенә җиткән иде, гаҗәеп бер яңа тавыш ишетеп, тукталып калды. Зәңгәр күккә караса, тезелешеп торналар үтеп бара иде.

— Тор-рыйк, Илгизәр, тор-рыйк, — дип кабатладылар алар.

Торналар күздән югалырга да өлгермәде, әллә каян кыр казлары килеп чыкты:

— Кый-гак, кый-гак, кыюрак, Илгизәр, кыюрак, — дип, болары да Агыйдел ярларына таба юл алды.

...Күк йөзе тәмам бушап калгандай булды. Илгизәр, әлеге кыр казларын кабат күрмәмме дип, Агыйдел өстендәге зәңгәрлеккә текәлгән иде, югарыда — бик биектә кечкенә бер нокта күреп алды. Ул, бер кечерәеп, бер зураеп, әле аска төшеп, әле өскә менеп, кояш нурларында уйный иде. Менә ул инде Илгизәрләрнең алма бакчасы өстендә үк. Агач төбендә яткан Илгизәрне күреп алды булса кирәк, аның баш очында ук талпына-талпына сайрый башлады:

— Үрел ми-ңа, үрел миңа... Яле, суз кулларыңны, Илгизәр, — дип кабатлый иде ул гүя.

Әнә ул бөтенләй якын ук килде. Илгизәр, аны тотмакчы булып, кулларын сузды... һәм, үзе дә сизмәстән, аякларына басты. Тургай тагы да якынайган кебек тоелды Илгизәргә.

Әнисе өйдән чыкканда да ул шулай басып тора иде...

— Кара әле, кошлар минем улыма «тәпи» алып килгәннәр ләбаса,— диде әнисе, куанып.— Рәхмәт сезгә, кошкайлар!

# Минем әни

Сугыштан соңгы еллар иде. Күпләребезнең әтиләре, абыйлары фронт кырларында башларын салды, исәннәре дә кайтып җитмәгән... Шуңа күрә авылдагы күпчелек эшләр әниләребез җилкәсендә. Минем әнием дә җәен кырда, кышын терлекләр янында булды.

Әле дә хәтеремдә. Кояшлы матур көн иде... Әнием, ничектер бер ара табып, төшке ашка кайтты. Шул вакыт мин аның күзләрендә беренче тапкыр ачу билгесе күргәндәй булдым:

— Туп тибүне ташларга вакыттыр, улым, йортка ярдәм итәргә кирәк. Әтиең синең кебек чагында инде сука сукалаган, икмәк үстергән. Озын Куак янында чапкан печәнебез бар. Бүген эштән соң алып кайтырбыз, төяшергә кил. Өстә таптап булса да торырсың...

Малайлар белән кузна уйнап, кич җитүен сизми дә калганмын. Кузналарны өйалды астына кертеп ташладым да әнием чакырган җиргә — Озын Куак буена дип чыгып йөгердем.

Авыл башына җитәрәк Бәләкәй әби каршыма чыкты. Аның төсе киткән, нәрсәдер булган, ахры. Моңа кадәр Бәләкәй әбинең (исемен белмим, без, бала-чагалар, хөрмәт йөзеннән аны шулай дип йөртә идек) авырганын бер дә хәтерләмим. Тып-тып басып йөри торган нык кына карчык иде ул.

— Улым, — диде ул миңа, — әллә нәрсә булды бит менә... йөрәгем чәнчә, хәлем юк... Фельдшер апаңны гына чакырып кил әле.

Фельдшер апаны? Авылның бөтенләй икенче башында тора бит ул. Нишләргә? Тыңласаң да кыен, тыңламасаң да... Юк, әбинең сүзен тыңламый ярамый. Алай дисәң, әнием нәрсә әйтер? Ул да көтәдер инде. Соңга калам бит. Юк, кичерер әле. Әбигә дә ярдәм итәргә кирәк ич...

Мин фельдшер апаны чакырырга йөгердем. Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, ул өйдә юк иде. Бер авыру бабай янына киткән. Аны эзләп табып, Бәләкәй



әбинең хәлен аңлатып биргәнче шактый вакыт үтте.

Без килеп җиткәндә, әбинең төсе киткән, сулышы ешайган иде.

— Рәхмәт, улым, — диде ул, бераз хәл алгач. — Әниең бәхетле шул синең. Кул арасына керердәй менә нинди улы үсеп килә. Рәхмәт, улым, рәхмәт!

Мин өйгә кайтып кергәндә, әни печәнне бушатып бетерә язган иде инде.

— Кермәсә дә керми бит сиңа... Кая югалдың? Көн буе кузна уйнап кемнең кеше булганы бар? — дип, караңгы чырай белән каршы алды ул мине. — Әнә Гөлчирә малае Зиннур басуга ук барган иде. Бәхетле кешенең баласы да адәм рәтле...

Мин еларга да иткән идем, әмма тешне кысып түздем, булган хәлне сөйләп бирдем. Ләкин нигәдер әниемнең күңеле йомшаган кебек тоелмады. Ул арбадагы печәннең соңгысын, сәнәк белән чәнчеп, абзар түбәсенә ыргытты да, кырыс кына:

— Бар, атны илтеп кайт, ичмаса, — диде.

Мин җирән биягә атландым да атлар абзарына элдерттем. Атны эчертеп, ат караучыга тапшыргач кына өйгә кайттым.

Ашыйсы да килми, йокы да качты. Әнинең хәтерен калдырмас өчен ашны бер-ике генә каптым да урынга менеп яттым.

Бераздан, мине йоклагандыр дип уйлаган, күрәсең, әнием яныма килеп утырды, иплəп кенә өстемә япты. Аннары кытыршы куллары белән башымнан сыйпады. Ә мин, йокламаган булуымны сиздереп, кымшанып куйдым.

— Йокла, балам, йокла! Ачуланып та ташлыйм үзеңне... Кешеләргә, бигрәк тә ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә ихтирамлы булу бик кирәк, улым, дөрес эшләгәнсең...

Бу сүзләрдән күңелем эреп китте, чәч төпләремнән әллә нинди җылы йөгереп узды. Түзә алмадым, берничә кайнар яшь бөртеге мендәремә тәгәрәде. Аларны әнигә күрсәтмәскә тырышып, мин юрган астына чумдым...

# Җаен таптык

Бервакыт без әни белән икәүләп Каенсарга — әбиләргә кунакка барырга җыендык. Әбием бик тә ярата иде балны. Шуңа күрә күчтәнәчкә дип бер савыт бал да әзерләдек.

Әнием үзе яраткан җирән атны алырга китте. Ул киткәч, бал савытын карасам, телсез калдым: ул ауган да, андагы бал арба төбенә агып беткән.

Нәрсә эшләргә? Күчтәнәчсез ничек кунакка барасың ди? Өйдә дә бал бүтән калмады. Бердәнбер умартаның балы кая җитсен ди?

Шул арада әнием дә кайтып җитте. Мин аны:

— Әнием, бал түгелгән бит... — дип, еларга җитешеп каршы алдым.

Әнием исә:

— Кайгырма, балам, хәзер кортлар җыеп бирер безгә ул балны... Тик әбиеңнәргә кунакка гына бүген барып булмас, иртәгә барырга туры килер, — диде дә елмаеп куйды.

Шуннан без арбаны умарта янынарак тарттырып куйдык. Күп тә үтмәде, бал кортлары бал исен сизеп алдылар. Алар бер-бер артлы арба төбенә килеп куналар да бал төяп умартага юнәләләр. Тирә-якта көне буе аларның шат авазы яңгырап торды:

— Без-без, эш-ли-без-з, балны без иртәгә үк әзерләп тә бирер-без-з...

Бал кортлары чынлап та сүзләрендә тордылар. Иртәгесен без әни белән кәрәзләрне умартадан алдык та бал суырттык. Бал савыты хуш исле бал белән тулды.

Шуннан соң без, бал кортларына рәхмәт укый-укый, яңадан юлга чыктык.



## Бигрәк тәмле бәрәңге

Төш алдыннан әни безне ашарга чакырды. Иртәдән бирле агач төпләрен йомшартып шактый арылган иде. Тиз генә кулларны юдым да өстәл артына уздым. Борынга тәмле бәрәңге исе килеп бәрелде. Берсен авызга алып кабуга, ул шикәр кебек таралып та китте.

— Бигрәк тәмле итеп пешергәнсең, әни, бәрәңгене, — мин әйтәм.

Минем сүзне ишетүгә, моңарчы диванда кырын ятып торган энем дә сикереп торды һәм тизрәк өстәл янына узды. Ләкин бәрәңгене кабып карауга, кәефе кырылды.

— Алдакчы, тәмле дигән була тагы, — дип, кире диванга барып ятты.

— Ашыйсың килмәсә, улым, — диде аңа әни, — сиңа да бераз эш бар иде. Безнең бер кисмәк буш тора. Көн бик эссе, коргаксып китүе бар. Шуны гына тутырып керсәң иде...

Иртәдән бирле диванда сузылып яткан энем теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалды.

Кисмәккә аз дигәндә дә кырык чиләк су сыя. Без чыкканда, энем аны тутырып бетерә язган иде инде. Ул соңгы чиләк суны бушатты да өйгә йөгерде. Бераздан тәрәзәне ачкан да миңа кычкыра:

— Абый, абый, дим, бәрәңгене гел суытып кына ашарлык икән. Шундый тәмләнгән хәзер...

Мин борын астыннан гына елмаеп куйдым. Ә әни исә:

— Аша, улым, аша, — диде, — эшләп ашагач, суынса да тәмле була ул шулай.





## Йокы качкач...

Берәр кая китәсе булса, әнием мине һәрчак әбиләргә илтеп куя иде. Бу юлы да шулай булды. Әби белән икәү генә калдык. Әллә бертуктаусыз сикергәләп йөрүем ошамадымы, әллә инде болай гына, әбием мине йокларга салды. Тик минем һич кенә дә йоклыйсым килми иде. Күземне дә йомып карыйм, санаган да булам. Юк, йоклап булмый. Моны әби дә күреп алды:

— Нәрсә, йокың качты мәллә? — диде ул миңа.

— Әйе, — мин әйтәм, — качты, ахры...

— Тор әле, алайса, — диде әбием, — яшелчә бакчасына кереп карыйк әле. Йокым качканда, мин гел шуннан таба идем аны.

Ни эшлисең, чынлап та эзләп карарга кирәк, дидем мин эчемнән генә. Әби, бакчага керү белән, кишер түтәле янына тукталды.

— Бу түтәл бигрәк куе, йокың шушында качмады микән? Тик йокыңны эзләгәндә, кишерләремә тимә, чүпләрен генә йолкып ташла. Шулай итеп сирәкләсәң, аның арасыннан йокы түгел, бөтен нәрсәне күреп була...

Әбием әйләнеп килгәндә, бер түтәлне сирәкләп бетергән идем инде.

— Бернинди дә йокы күренмәде монда, — мин әйтәм.

— Алайса, улым, менә бу түтәлдән эзләп кара, — диде әби, — бәлкем, биредәдер...

Икенче түтәлне бетергәндә, күзләр арыды, билләр талды, гел урынга авасы килә башлады... Минем хәлне әби дә күреп алган икән, ул мине иягемнән йомшак кына тотып, күзләремә текәлде дә:

— Чынлап та, йокы кишер арасында булган икән, улым, — диде. — Шуннан ул әнә синең күзләреңә кергән. Бар, тизрәк ят йокларга, качыра күрмә тагын...

Шуннан башымны мендәргә куеп өлгердемме-юкмы, хәтерләмим, изрәп йокыга киткәнмен...

# Гыйльми маҗаралары





## Белемле — менне егар

Көн гаҗәп матур иде.

Гыйльми белән Белми көндәгечә иртүк торып урамга чыктылар. Гыйльми әйтә:

— Әйдә болынга төшәбез, — ди.

Ә Белми киресен сукалый:

— Монда гына калыйк, кузналы уйнарбыз, — ди.

Моңа Гыйльминең ачуы килде:

— Бетмәде инде шул кузналарың, — диде ул, — бер китап укыганың юк. Табигатьне — болыннарны, бөҗәкләрне, җәнлекләрне бар дип тә белмисең, алар турында уку түгел, хәтта тыңларга да теләмисең.

— Йә, син укыйсың да ди. Аңа карап кай җирең артык? — дип кабарынды Белми. — Кичә әнә бөҗәкләр,

әллә нинди кортлар турында укып көнеңне үткәрдең. Нигә кирәк алар? Ә мин, ичмаса, малайлардан бер кәрзин кузна оттым.

— Синең үз кирелегең инде. Көчләмим, теләсәң нишлә. Ә мин бүген болынга төшәм. Төшкә кадәр су буенда балык тотам, кошлар сайравын тыңлыйм, — диде Гыйльми, кырт кисеп. — Ә син кузна җый!

Шуннан ул, тиз генә өйләренә кереп, сумка белән кармакларын алды да болынга юнәлде.

— Гыйльми, Гыйльми, дим, мине көт... Никтер синнән каласым килми бүген.

Менә алар инде тын гына агып яткан Ык буенда. Тирә-як ямь-яшел куаклык, кошлар сайрый, аратирә исеп куйган җил белән борынга чәчәк исе бөркелә. Нәкъ шул вакыт кайдадыр бик еракта гөж-ж-ж килгән тавыш ишетелде.

— Самолет бу, — диде Белми һәм күп белгәндәй өстәп куйды: — Өрңа марка.

— Бер дә самолетка охшамый шул бу, энекәш,— диде Гыйльми.



Икесе дә зәңгәр күккә текәлделәр. Шулчак әле шактый гына еракта тузан өермәсенә охшаш нәрсә күренде.

— Җил шаяра, — диде Белми, акланып. — Самолет дип торам тагын...

Гүләү көчәйгәннән-көчәя барды. Шулчак Гыйльми әле кичә генә бал кортлары турында укыган китабын исенә төшерде:

— Җил түгел бу, Белми, ә умарта кортлары күч аерган, белдеңме?

Күч туп-туры малайлар өстенә килә иде. «Корт» дигән сүзне ишетүгә, Белми урыныннан сикереп торды да, кармакларын да алырга онытып, авылга таба чапты.

— Йөгермә, йөгермә, дим, тик кенә тор, кузгалма! Харап буласың, малай, ышан миңа, тукта! Җиргә ят!

Әмма Белми ишетергә дә теләмәде. Ул инде корт чагуның нәрсә икәнен белә иде. Дөрес, ул чагында бер генә корт чакты, алай да өч көн сызланып йөрде. Ә бүген алар өстенә әнә никадәр корт килә. «Гыйльмине генә чаксалар ярар иде, аны бит әле бер генә кортның да чакканы юк», — диде Белми эченнән һәм качып котылырга уйлады.

Бөтен көченә йөгерә Белми. Йөгергән саен, гүләү көчәя генә бара. Бөтен тәненә салкын тир бәреп чыкты, аяклары кая басканын да тоймый башлады. Кичә генә Гыйльми аңа кайбер усал токымлы кортларның кешене чагып үтерүе турында сөйләгән иде. Шул сүзләр исенә төшүгә, тәмам йөрәге алынды Белминең. Беренче кортның чигәсенә килеп сарылуы булды, һушын җуеп, түмгәккә капланды.

Ярый әле һушын җуйды, югыйсә, чәбәләнеп, бөтенләй харап булуы бар иде. Күч аның җилкәсен, баш түбәсен сыргадай сырып алды.

Гыйльми исә тиз генә тал ботаклары сындырып себерке ясады да аны суга манчыды һәм, сумкасын алып, Белми янына килде. Сак кына иелеп, Белминең өстендәге

сырганы иплəп сумкасына сыпырып төшерде. Аннары сумканы читкəрəк этəрде, калган кортлар да шунда — сумкадагы аналары янына җыелдылар.

Башын салкын су белəн чылаткач кына аңына килде Белми. Һəм, як-ягына карангалап, нəрсəнедер исенə төшерергə азапланды. Булган хəллəр төш тə кебек, өн дə кебек иде. Үзенең түмгəкле урында ятканын күргəч, өн булгандыр, ахрысы, дип уйлады. Аннары, Гыйльмигə карамыйча гына:

— Кортлар очып та киттелəрмени инде? — дип сорап куйды.

Гыйльми исə китап сөймəс дусты Белмине ымлап кына сумка янына чакырды:

— Менə алар... Синең башыңнан җыеп алдым.

— Болай эшлəргə икəнен каян белдең?

— Хəтерлисеңме, — диде Гыйльми, — беркөнне мин сиңа бер китап укырга тəкъдим иткəн идем. Ə син телəмəдең... Аннан бал кортлары турында күп нəрсə белергə була иде. Белемле — меңне егар, Белми дус. Шуны онытма.

Белми, оялудан үз-үзен чак кулга алып:

— Миңа укытырсың əле шул китабыңны, ярыймы? — диде.

Күч гаҗəп куəтле булып чыкты. Көзен алар Гыйльмигə бер тəпəн бал бүлəк иттелəр.



## Белми дисәң дә Белми

Ял көнне Белми энесе Үсәрне ияртеп бакчага — әнисе янына килде. Бу бакчаны әле узган ел гына алганнар иде. Идел суы бакчага терәлеп үк ага. Гаҗәп матур җирдә урнашкан. Тик яңа бакча булгач, эше күп иде. Азрак буш вакыты булдымы, әниләре шунда ашыга...

Уллары килгәндә, әниләре бу юлы да түтәлләр ясап йөри иде. Аларны күргәч:

— Менә булышчыларым да килеп җитте. Рәхмәт сезгә, балакайларым, — диде әниләре, елмаеп.

Әмма Белми булышырга бик ашкынып тормый иде. Эш турында сүз чыгуга, тизрәк бер сәбәп табып, өйгә кереп китте. Энесе Үсәр исә, кулына кечкенә тырма алып, әнисе казыган түтәлләрне тигезләргә кереште. Кечкенә шул әле, эшләргә теләге булса да, бик үк әйбәт килеп чыкмый. Шулай да әнисе куанып бетә алмый...

Берүзенә генә өйдә утыру Белмигә читен булды, ахрысы. Бераздан ул да бакчага чыкты.

— Кем шулай тырмалый инде? — диде ул, Үсәрне үртәп. Аннары тырманы алмакчы булды. Энесе бирмәде.

—Үзем... комачаулама, — диде.

Белмигә нәрсә, шул гына кирәк иде. Ике кулын кесәсенә тыкты да сызгырына-сызгырына су буена китеп барды.

Эше беткәч, Үсәр дә Белми янына — яр буенда тезелешеп киткән көймәләрнең берсенә килеп утырды. Көтмәгәндә су өстендә бер балык уйный башлады. Белми исә, балыкны якыннанрак күрергә теләп, җәһәт кенә урыныннан торды да бер көймәдән икенчесенә сикерде. Аның артыннан сикерим генә дигән иде, көймә чайкалып китте дә, Үсәр кием-ние белән суга чумды.

Ярый әле якында гына Гыйльми көймәдә йөзеп йөри иде. Ул суга чумган Үсәрне күрүгә кычкырып җибәрде:

— Белми, энең бата бит, коткар тизрәк!



Белми исә көймә читенә утырган да бер чумып, бер калкып азапланган энесен тыныч кына күзәтә бирә.

Гыйльми түзмәде, шундук көймәсеннән суга сикерде һәм Үсәргә таба йөзеп китте. Тиздән инде Үсәр Гыйльминең ышанычлы кулларында иде.

Шау-гөр килеп халык җыелды. Үсәрнең әнисе үксеп елый, калганнар аны юата: «Берни дә булмады Үсәреңә, әнә елмая да инде», — диләр.

Гыйльми исә, йодрыкларын төйнәп, Белмигә омтылды:

— Нәрсә син, энең харап була иде бит! Хәтта коткарырга да уйламыйсың...

Ә Белминең исе дә китми:

— Йөзәргә өйрәнсен дидем. Комачауламаска тырыштым. Түтәл ясаганда үзе бит комачауламаска кушты, — диде.

Гыйльми исә, көләргә дә, ачуланырга да белмичә, Белминең күзләренә озак кына карап торды. Уйнап түгел, чынлап сөйли бит! Менә сиңа, Белми дисәң дә Белми!..



## Туган көнен белән, Гыйльми

Иртәгә Гыйльминең туган көне. Шул уңай белән Белми аңа нинди дә булса яхшылык эшләргә, берәр кирәкле әйбер бүләк итәргә уйлады. Ә нәрсә бүләк итәргә икән соң? Ни белән сөендерергә икән дус кешене? Тукта, бервакыт Гыйльми гөмбәләр турындагы китап белән кызыксынган иде бит. Димәк, ул аңа кирәк. Ә андый китапны Әхмәттә күргәне бар иде Белминең. Шуның янына барып карарга кирәк, булмаса...

— Саумы, Әхмәт, — диде ул. — Озак сөйләшеп торырга вакыт тар. Бик кирәкле йомыш белән килгән идем әле үзеңә. Син Гыйльмине беләсең инде, хәтта дуслар да. Менә шул... Гыйльми гөмбәләр турында китап сораган иде. Ә синдә, Әхмәт, андый китап бар иде кебек?

— Бар иде дә, хәзер юк инде. Апама бүләк иттем мин аны.

— Тагын таба алмыйсыңмы соң?

— Табарга була булуын... Тәк... Син Айрат янына барып кара. Әхмәт җибәрде, диген. Мине яхшы белә ул. Еш кына тәмле конфетлар белән сыйлый идем үзен. Әни конфет фабрикасында эшләгәч, җәлмени... Давай, син шунда барып кара...

— Хәерле кич, — диде Белми, Айратны өендә очратып. — Мин сиңа, беләсеңме, кемнән? Теге конфетлар патшасы Әхмәттән.

— Беләм, беләм мин аны, — диде Айрат.

— Безгә гөмбәләр турында китап бик тә кирәк иде. Дөресрәге, миңа түгел, Әхмәтнең дусты Гыйльмигә.

— Булса, җәл түгел иде дә, юк шул. Андый нәрсәләрне миңа һәрчак Азат табып бирә иде. Шуңа барып кара син, дус кеше. Айраттан килдем, диген. Мине яхшы белә ул. Үзе балыкчы. Ә балык тоту өчен кирәк-яраклар миндә аз түгел. Апам «Балыкчы» кибетендә эшли ич. Ярый, миннән сәлам тапшыр аңа!

Бәхеткә каршы, Азат та өйдә булып чыкты.

— Мин сиңа Айраттан, — диде Белми. — Онытмагансыңдыр бит? Гыйльминең дусты Әхмәт тә еш була аларда. Ә апасы «Балыкчы» кибетендә эшли.

— Ә-ә, төшендем... Ни йомыш иде соң?

— Гөмбәләр турында китап кирәк иде. Дөресрәге, миңа түгел, ә Айратның дусты Гыйльмигә.

— Булса, жәл түгел иде түгелен. Андый китапларны мин үзем Иректән ала торган идем. Син шуңа барып кара. Минем өчен барысын да эшли торган малай. Маркаларның ниндиен генә табып бирмәдем инде мин аңа. Сәлам әйт! Ярый, хуш!

Ирекләргә керү белән, Белми сүзен шуннан башлады:

— Маркалар җыючы Азаттан сәлам, — диде ул. — Сиңа йомыш зур безнең. Гөмбәләр турында китап таба алмассың микән?

— Юк шул, дус кеше. Әни китап кибеteннән китте шул. Ул хәзер кинотеатрда билетлар сата. Яхшы фильмнарга билет табып бирә алам. Ә китап турында син Аликка әйтеп кара. Аның әнисе китап кибетендә эшли. Миннән күп итеп сәлам әйт. Иртәгә бик шәп яңа фильм күрсәтә башлыйлар, диген. Безгә килсен.

Белми, кош тоткандай куанып, Аликларга керде. Ләкин, үч иткәндәй, бүген генә үзе булган кайбер малайларның исемнәре башыннан чыккан иде.

— Хәерле кич, — диде Белми, нәрсәдән башларга белмичә. Аннары, ашыгып: — Мин Гыйльмидән, түгел лә, Әхмәттән булам, — диде.

— Андый малайны белмим мин, — диде Алик.

— Гыйльми булып Гыйльмине белмисеңме? — дип сүз куертмакчы булды Белми. Ләкин ул уеннан кире кайтты. — Гыйльминең үзен белмәсәң, аның дусты Әхмәт... Әнисе конфет фабрикасында эшли. Әхмәтнең дусты Айрат. Апасы «Балыкчы» кибетендә эшли. Ә Айратның дусты Азат. Азатның дусты төрле-төрле маркалар җыючы... исемен онытТым бит...

— Мондый малайларны да белмим, — диде Алик. — Сезгә нәрсә кирәк соң?

— Гөмбәләр турында китап кирәк безгә. Менә шул. Әнисе кинотеатрда эшли торган малай җибәрде мине монда. Сине кино карарга чакырды.

— Ә-ә, шулай диләр аны. Димәк, Иректән килдең? Табабыз аны. Ничәү кирәк? Шул син санап киткән малайларның барысына дамы?

— Юк, бер генә китап, бер генә...

— Иртәгә иртән кереп чык. Әзер булыр.

Белминең шатлыгы эченә сыймый иде. Димәк, Гыйльмигә сюрприз булачак. Ул өенә ничек кайтып җиткәнен дә сизми калды.

Әхмәт исә үзе янына Белми кереп чыкканнан соң уйга калды. Ә нигә кадерле китапны үзе эзләп бирми әле ул? Гыйльми дусты өчен аягы калырмы? Җәһәт кенә киенде дә белгән-күргән дуслары янына юнәлде. Әхмәткә китапны дуслары тиз таптылар. Ә иртәгесен инде ул, гөмбәләр турындагы китапны кыстырып, Гыйльми янына китте.

— Кичә минем янда Белми булган иде, — дип башлады ул сүзен.— Гөмбәләр турында китап сорагансың икән, рәхим ит!

Гыйльми башта аптырап калды. «Мин бернинди дә китап сорамадым», — дип әйтмәкче булган иде, тик Белмине дә, Әхмәтне дә уңайсыз хәлдә калдырасы килмәде.

— Рәхмәт, Әхмәт, кайгыртуың өчен зур рәхмәт,— диде ул.

Әхмәт чыгып китүгә үк, Белми дә килеп җитте. Аның да култык астында шундый ук китап иде. Ул әле Гыйльмигә, әле өстәлдә яткан гөмбәләр турындагы китапка карап, сүзсез калды. Аннары кинәт кенә йөгереп килде дә Гыйльминең кулын кысты:

— Туган көнең белән, Гыйльми!



# Сөйләшә белүче кырмыска

Бабасы Белмине бакчачы итәм диде. Ул бүген килергә тиеш. Бакча бик тә матур урында урнашкан. Быел да алмагачлар шау чәчәккә күмелде. Нәни генә алмалары да күренә инде. Белми көн дә күзәтә үзләрен. Энекәше Үсәрдән вакытында су сиптертә, төпләрен йомшарттыра. Үссеннәр генә. Тик нишләптер бер алмагачның яфраклары куырылып, йомарлана башлады, үсүдән туктады, очлары зәгыйфьләнде.

«Нигә болай азапланасың? Кем куыра яфракларыңны, алмагачкаем? — ди Белми. — Ни җитми сиңа? Их, сөйләр идең дә, телең юк шул синең...»

Куырылган яфракларны ул кулына алды да акрын гына ача башлады. Шулчак яфрак арасыннан бер кырмыска йөгереп чыкты. Аннан икенчесе, өченчесе...

— Әһә, сез җәфалыйсызмы минем алмагачымны? Хәзер үк юк итәм үзегезне. — Ачуы чыкты Белминең, уйлапнитеп тормады, иң алдан йөгергән Нечкәбилне эләктереп алды. Сытыйм гына дигән иде, Нечкәбил, Белминең күзләренә текәлеп, иреннәрен кыймылдата, гүя нидер сөйли башлады. Нинди телдә сөйлидер, һич аңлашылмый.

— Мине кырмыскаларча сөйләшергә өйрәтмәделәр, безнеңчә сөйлә,— диде Белми, җитди генә. Шулай да кызганып куйды ул аны. Әллә инде, гафу ит, абзыкаем, башка кабатламам, ди. Әллә, исән калдырсаң, яхшылык итәрмен, ди... Уйлап карасаң, кырмыскаларның да яхшы яклары күп бит...

Шулчак кырмыска нәкъ безнеңчә сөйли башламасынмы! Әйе, әйе, нечкә генә тавыш белән сөйли башлады бу: «Абзыкаем, — ди, — безнең энә очы кадәр дә гаебебез юк. Алмагачларны газаплаучы яшел борчаларның суын гына суырабыз без. Зинһар, тимә, җибәр безне...»

Ул соңгы сүзләрен бабасының тавышына шундый охшатып әйтте, Белми аптырап ук калды хәтта. Шунда колак артында гына бабасының кеткелдәп көлгәне ишетелде. Кырмыска булып бабасы сөйләгән икән. Оялды да соң Белми аны күргәч, бит очлары әле дә булса янып тора...





## Баллы кар

Кулына берәр тәмлерәк нәрсә эләктеме, Белми энесеннән читкәрәк китү ягын карый. Чөнки тәмле нәрсә күп булмый, ә аз нәрсәне энесе белән бүлешәсе килми аның. Гадәте шундый икән, ничек итеп бүген генә үзгәртә алсын ул аны? Әле генә дәү әнисе биргән баллы карны тәмләп суырып утырганда, үч иткәндәй, энесе Үсәр күзенә чалынды. Белми шунда ук ялт итеп куаклар арасына чумды һәм тиз генә әйләнеп тә чыкты.

— Абый, абый, — диде энесе аңа, — кулыңда баллы кал бал иде түгелме соң? Әллә яшелдең инде?

— Яшерде ди сиңа… Каян килсен ди миңа баллы кар? Тәмле нәрсә күбрәк сиңа эләгә бит. Кечкенәм, дип, төпчегем, дип, әни дә сиңа алып бирә, әти дә. Ә мине, зур инде син, диләр. Менә шулай, энекәем.

— Алдамасана, мине күлмәде дип, сукыл дип белдеңме әллә?

Болар сүз көрәштергән арада, якындагы куаклар арасында бер карга чүпләнеп йөри иде. Ул кинәт куанычын яшерә алмый кычкырып җибәрде:

— Кар-р, таптым кар, — диде ул һәм, баллы кар савытын эләктереп, тупыл башына кунды.

Чынлап та, ямьле җәй уртасында сап-салкын кар тапкан иде ул. Аның да ниндиен әле, баллысын, тәмлесен.

Белми, каргага бөтенләй игътибар бирмичә, энесе белән бәхәсләшүен дәвам итте:

— Теңкәмә тимә инде, Үсәр! Бернәрсә дә яшермәдем, дим бит…

Үсәр исә, аңа ышанмыйча, туп-туры куаклар арасына кереп китте. Калган баллы карны энесе эләктергәнче дип, Белми дә аның артыннан куаклыкка ташланды. Эзлиләр, эзлиләр, таба алмыйлар. Белми кабалана. Югыйсә менә шушында гына куйган иде бит. Кая китәр икән? Шулай да үзе дулкынлануын энесенә белдермәскә тырыша:



— Әйттем бит мин сиңа яшермәдем дип, ә син ышанмаган буласың. Хәзер ышандыңмы инде?

— Яшелмәгәч, нигә үзең бик кабаланып эзләдең соң? Саланлансаң, шулай була ул менә: үзеңә дә юк хәзел, миңа да...

Шулчак, Үсәрнең сүзләрен раслагандай, агач башындагы карга аваз салды:

— Кар-р-р! Эреп беткән баллы кар!

Белми карганы күрмәкче булып тупыл башына текәлгән иде, буш баллы кар савыты аларның алдына ук килеп төште.



## Йомышын төшкәч

Тирләп салкын су эчкән иде Белми, нык кына салкын тидерде, тамагы авырта башлады. Көннәр үтте, авырту һаман басылмады. Гыйльми ярдәм итәр иде итүен, тик узган атнада ачуланышканнар иде шул. Ни булса шул булыр дип, Белми иске дусты янына барырга булды. Бу бәладән коткарса, ул гына коткара ала.

Белми килгәндә, Гыйльми умарта бакчасында бал кортларына шикәр суы биреп йөри иде. Иске дустының капкадан керүен күргәч, ул баллы суны агач төбенә куйды да кулларын сөртә-сөртә Белмигә каршы юнәлде:

— Кайда югалдың син, малай? — диде ул. — Килмисең дә. Авырмагансыңдыр бит?

Белми исә сүзне нәрсәдән башларга белми азапланды. Ни өчен килгәнен башта ук әйтеп салса: «Үзеңә кирәк чакта гына йөрисең шул син», — дип уйлавы бар Гыйльминең...

— Юк ла,— диде ул. Аннары сүзне икенчегә борды.— Бал кортларын сыйлыйсың, ахры? Син инде кайчагында арттырып ук җибәрәсең. Җәй уртасында, бөтен дөнья чәчәктә утырганда, шикәр суы биреп, кортларны узындырасың түгелме?

Белми үзенә калса шәп әйттем дип уйлады, ахрысы: Гыйльми генә түгел, Белми дә кайбер нәрсәләрне белә дигәндәй, астан гына елмаеп куйды.

Гыйльминең моңа бер дә исе китмәде.

— Әйе, шикәр белән сыйлыйм, кыярларны коткарырга кирәк, — диде.

— Ничек инде кыярларны?.. — дип башлаган иде Белми, тик шикәр суында яткан кыяр чәчәкләрен күргәч тынып калды.

Нәрсә кылана инде тагын? Әкәмәт тә кеше бу Гыйльми. Кыяр чәчәкләрен өзеп суга салгач, аннан нәрсә үссен ди?

Белминең күз алдында шикәр суына бер-бер артлы бал

кортлары очып куна башлады. Алар балны җыялар да очып китәләр...

Белми карап торды-торды да, ачуы чыкты:

— Алдамасаң күңелең булмыймы әллә синең, Гыйльми? Кыярларга түгел, кортларга куйгансың бит шикәр суын.

Гыйльми көлемсерәде:

— Эшнең хикмәтен белсәң, бер дә болай дип әйтмәс идең. Әнә кара! Ширбәттә нигә кыяр чәчәкләре ята дип уйлыйсың?

— Белмим, берни дә белмим, — диде Белми.

— Әнә теге ике түтәлне күрәсеңме? Ул — минем кыярларым. Тик кыяры сирәк күренә, кыярланмыйлар. Чөнки тирә-якта чәчәкләр шулхәтле күп, бал кортлары кыяр чәчәкләренә бөтенләй игътибар бирмиләр диярлек. Менә шуларның игътибарын арттырмакчы, дөресрәге, хәйләләмәкче булам, Белми дус. Әнә, күрәсеңме, бал кортлары кыяр исе сеңгән шикәр суын ташыйлар. Бу аларга җиңел бирелә. Шуңа күрә кыяр чәчәге исе аларның миенә сеңеп калачак. Күрерсең, иртәгә алар барысы да минем кыяр түтәлемдә булырлар. Төшендеңме инде?

Ниһаять, Белмигә йомышын әйтү өчен уңай вакыт җитте кебек.

— Бер дә белмәгәнең юк инде, Гыйльми дус, — диде ул, елмаерга тырышып. — Ә мин, юләр, шуннан файдалана да белмим. Бәлки, әле син минем әниемнең тамагын ничек дәваларга икәнен дә әйтерсең.

— Әниең авырыймыни? — диде Гыйльми. — Ә мин аны кичә генә күргән идем. Ул: «Улым Белминең тамагы бик авырта», — дип зарланды. Ә мин, килсен, чарасын табарбыз, дигән булдым тагын...

Белминең колак очлары кызарып чыкты.

— Гыйльми дус, коткар мине, тамак чиреннән дә, ялган сөйләүдән дә коткар...

— Тамагыңны дәвалarбыз анысы, — диде Гыйльми, көрсенеп, — тик менә икенче чирдән, ай-һай, дәвалап

булыр микән сине? Анысыннан котылу ягын үзең кара инде.

— Ә тамакны ничек төзәтәсең?

— Аның өчен умарта җилеме — прополис кирәк. Шуны майда эретеп капкаласаң, авырту басылыр. Умарта кортлары — шәп бакчачылар гына түгел, менә дигән докторлар да алар.

Гыйльми умартасына таба юнәлде. Кортлар очып чыгып йөри торган тишекне зуррак ачып куйды. «Ник алай эшлисең?» — дигәч, Белмигә: «Иртәгә күрерсең», — дип кенә җавап бирде.

Иртәгесен Гыйльми белән Белми бакчага чыктылар. Бал кортлары кыяр түтәлләре өстендә гөж килә иде.

— Әнә кичәге ширбәтле кыяр суы ничек ошаган үзләренә. Димәк, кыяр мул булачак, — диде Гыйльми.

Аннары умартага юнәлделәр. Бал кортлары зур итеп ачып калдырылган ярыкны бөтенләй кечерәйтеп куйганнар иде.

— Кортлар өчен зур ярыкның кирәге юк,— диде Гыйльми.— Шуңа күрә кортлар аны, бал урлаучы бөҗәкләр кермәсен өчен, прополис белән сылап кечерәйткәннәр. Хәзер мин прополисны кырып сиңа бирәм дә ярыкны элеккечә итеп калдырам. Аның бер зыяны да юк.

Белми, прополисны алгач, Гыйльмигә рәхмәт укып, эчтән генә башкача бер дә алдашмаска ант итә-итә өйләренә йөгерде...



## Гөблә ширбәте һәм кырмыска

Ул көнне Белми Гыйльмиләр дачасында кунды. Гыйльми иртәрәк торды да барлык куакларны карап, барлап чыкты. Барысы да тәртиптә иде. Тик иң яшь алмагачның яфракларын гына ямь-яшел бетләр — гөбләләр сыргадай каплап алган. Яннарында вак кына кырмыскалар кайнаша...

Белми уянганда, Гыйльми алмагач яфракларын сабын суы белән юып йөри иде инде. Су белән бергә йомарланып җиргә гөбләләр һәм кырмыскалар коела.

— Нәрсә эшлисең син, белем иясе? — диде Белми, гадәттәгечә күп белгәндәй. — Бакча санитарлары — кырмыскаларны харап итәсең бит!

— Ялтыраган һәрнәрсә алтын булмый ул, Белми дус,— диде Гыйльми. — Кырмыскаларның да төрлесе була: файдалысы, зыянлысы, корткычларны яклаучысы...

— Корткычларны ничек якласын ди инде кырмыска. Киресенчә, урманнарны, бакчаларны төрле бөҗәкләрдән саклый алар. Үзең дә шулай ди торган идең бит.

— Анысы шулай. Кырмыскаларның да төрлесе була шул. Бу кырмыскалар гөблә бүлеп чыгарган татлы шәрабны бик тә яраталар. Гөблә кайда, вак кырмыскалар да шунда. Кырмыска гөбләнең култык астын мыегы белән аз гына кытыклап алса, баллы шәраб әзер. Рәхәтләнеп эч кенә. Шуңа күрә дә кырмыскалар гөбләләрне үз итәләр, кыенлыклардан коткарып калырга тырышалар.

Шулчак бер кырмыска гөбләне җайлап кына иңенә салды да алмагач кәүсәсе буйлап аска йөгерде. Аннан күрмәкче, бүтән кырмыскалар да, яшь яфракларга сырышкан гөбләләрне эләктереп, сабын суы белән эшкәртелгән алмагачтан кача башладылар

— Әнә күрдеңме инде, — диде Гыйльми, — ничек оста коткара алар гөбләләрне...

Белми, тын да алмый, кырмыскаларны күзәтә башла-

ды. Тегеләре исә, җиргә төшкәч тә, күтәргән гөбләләрен җибәрергә ашыкмадылар. Киресенчә, төрле каршылыклар, чокырлы урыннарны үтеп, янәшәдәге алмагачка юнәлделәр. Әнә иң алдан киткән кырмыска янәшәдәге сабын суы белән эшкәртелмәгән алмагач кәүсәсе буйлап бераз өскә күтәрелде дә туктап калды. Үзе артыннан килүче кырмыскаларга, биредә куркыныч түгел, дип хәбәр салды. Тегеләре, дәррәү килеп, алмагачка ташландылар.

— Гыйльми, карале, кара, — диде Белми, хәйран калып. — Беренче кырмысканы әйтүем. Иң яшь яфракның астына керде дә үзе коткарган гөбләне җайлап кына шунда куйды.

— Ышандыңмы инде вак кырмыскалар китергән зыянга? Атна-ун көн дә үтмәс, кырмыскалар коткарып калган гөбләләр, үрчеп, бөтен яфракларны каплап алыр. Ә моңа юл куярга ярамый. Алмагачны шулардан да аралый алмагач, нигә бакчачы исемен йөртергә?!





## Урман имәнсез калмагае

Гыйльми белән Белми урманга кергәндә, бар дөнья җанланган иде. Якында гына бер поши юлны аркылы үтте, бер ботактан икенчесенә озын койрык тиен ук кебек атылды, корыган агачны тукран тукылдатып алды, малайларның каршысыннан гына төрле-төрле күбәләкләр куышып очтылар, пырхылдап бер төркем кошлар күтәрелде. Нинди генә үсемлекләр үсми дә, нинди генә кошлар сайрамый биредә! Әнә өзеп-өзеп күке кычкыра. Кинәт ул туктап калды.

Беренче булып Белми сүз башлады:

— Әгәр беләсең килсә, — диде ул, — күке минем әмерне көтеп туктады. Нәрсә кушсам, шуны эшли, ни сорасам, шуңа җавап бирә ул. Ышанмыйсыңмы? Алайса тыңла!

Белми әле генә күке кычкырган якка карап басты да сул кулын өскә күтәрде:

— Күке, күке, әйтче, хәзер миңа ничә яшь?

Күке Белминең әйтүен генә көткән кебек саный да башлады:

— Кәк-күк, кәк-күк, кәк-күк...

Белми исә күке артыннан бармакларын бөгеп барды: ... өчәү, дүртәү, бишәү, алтау, җидәү... Әй, ник туктадың әле син?

Белми җиденче бармагын бөккән килеш туктап калды. Аннары, Гыйльми алдында сынатмаска теләп:

— Белеп туктадың, күкем, рәхмәт, — диде. — Әле сигез яшь миңа иртәгә генә тула бит. Иртәгә сорасам, күрерсең, сигезне кычкырачак ул.

— Күке кычкырыр ул, — диде Гыйльми, — кычкырмый калмас. Тик синең мактанудан хурланып имәннәр ярылмасын, дим.

Аннары Гыйльми аланлыкта үсеп утырган имән янына туктады:

— Бу имәннең нигә ярылганын беләсеңме?

— Каян белим мин аны?

— Белмәсәң, тыңла. Бу имән турында әтием бер хикәят сөйләде.

Салкын кышны Хәйбул белән Зәйнул дигән кеше бирегә утынга килгәннәр. Көн салкын булса да, боларның утын кисәргә исләрендә дә юк икән.

— Өлгерермен әле, — дигән Хәйбул. — Минем бабай дүрт-бишәр колач җитмәс имәннәрне бер сугуда аударган.

— Нәрсә ул дүртәр-бишәр колачлы имәннәр, — дигән Зәйнул, юлдашын уздырырга теләп. — Синең бабаң кискән имәннәр минем бабай кискән имәннәрнең кече ботагы гына булган ул, кем...

Хәйбул, тагын да уздырыйм дип авызын ачса, чындырмы-ялгандырмы, менә шушы имән шартлап ярылган, ди. Шуңа күрә имәннәрне саклыйк, Белми дус. Берберебездән уздырып мактана башласак, урман имәнсез калмагае дип куркам...

Гыйльминең сөйләп бетерүен генә көткәндәй, күке кабат кычкыра башлады:

— Кәк-күк, кәк-күк, кәк-күк...

Белми исә тавышсыз-тынсыз гына бармакларын бөгә иде...



# Күзлекне кем урлаган?

Төш алдыннан кояш тотыла башлады. Көн караңгыланганнан-караңгылана. Малайлар кечерәя барган кояшка текәлделәр. Белми дә, бабасының өстәлдә яткан күзлеген эләктереп, ишегалдына чыкты. Күзлекне киеп карады да кире салды. Файдасы юк — барыбер күзләрне чагылдыра.

Бу чакта энесе Үсәр инде кояшны рәхәтләнеп күзәтә иде.

—Нәрсә аша карыйсың син? — диде Белми, энесен күреп.

Тегесе исә, бер дә исе китмичә:

— Яшькелт пыяла таптым... Кирәк булса, сиңа да өлеш чыгара алам, — диде.

Белми бабасының күзлеген койма тактасына элде дә энесе янына ашыкты.

Яшькелт пыяла аша каравы чынлап та бик уңай, рәхәт икән... Кояш инде урак кадәр генә калды. Әмма шуннан ары кечерәймәде... Җир белән кояш арасына туры килгән ай үз җаена тәгәрәде... Урак акрынлап киңәя барды. Яшькелт пыяла аша хәзер инде кояшның яртысы ук күренә. Тамашаның иң кызыклы җирендә генә Белминең бабасы бүлде:

— Белми улым, минем күзлекне алмагансыңдыр бит? Шушында гына куйган идем ләбаса.

— Алган идем, бабакай, — диде Белми, — хәзер китерәм.

Ләкин Белми күзлекне куйган урынында таба алмады. Койма буйларын, андагы песи борчагы үләне төпләрен карап бетерде, ары сугылды, бире сугылды, күзлек юк та юк. Югыйсә койма тирәсендә беркем күренмәде... Кая китәр икән?

Көтеп-көтеп күзлекне китермәгәч, Белминең бабасы үзе болдырга чыкты:

— Күзлекне кертәм, дигән идең бит... Кая югалдың тагын?



Белми башта ни әйтергә белми аптырап калды. Тик бертын сүзсез торганнан соң гына:

— Менә шушында койма башына гына элеп куйган идем, бабакай, — диде.

— Куйган булсаң, пәри урламагандыр лабаса, шундадыр. Юньләп кара, үлән арасына төшмәгәнме?

Белми дә эзли күзлекне, Үсәр дә килеп кушылды. Бабалары белән өчәүләп тә эзләделәр. Тик күзлек юк та юк.

— Бабакай, — диде Белми, ниндидер зур сер әйтергә теләгәндәй, — кояшның тарту көче зур, диләр. Шунда тартылмады микән?

— Тарту көче җитәрлек булса, иң элек синең үзеңне тартып алыр иде ул, улым, — диде бабасы, сукранып, — башың гүпчим буш диюем, күзлекне түгел, иртән ни ашаганыңны да белмисеңдер әле.

Шул вакыт капкада Гыйльми күренде.

— Исәнме, Сәхип бабай, — диде ул, — нәрсә югалттыгыз?

— Менә Белми йөри инде кеше кылмас эш кылып. Күзлегемне алып чыккан да каядыр куйган. Үзе дә таба алмый, без дә...

Гыйльми дә ярдәмгә кушылды. Дүртәүләп күзлек эзлиләр, һаман таба алмыйлар. Шулчак тупыл башында кемдер чүкердәп куйды.

— Чәүкә, — диде Гыйльми, — менә кем урлаган күзлекне.

Чәүкә белән янәшә генә ботакта Сәхип бабайның күзлеге эленеп тора иде.

## Викторинадан соң

Белми быел беренче класска укырга керде. Беркөнне ул мәктәптән борынын салындырып кайтты. Класста үткәрелгән викторинада бер бүләк тә эләкмәгән иде үзенә.

— Дөресен әйтсәң, гел шулай була ул, — диде Белми, әнисенә зарланып. — Һәрвакыт бүләксез каласың...

— Нинди сораулар бирделәр соң, улым? — диде әнисе, кызыксынып.

— Нинди дип, гап-гади генә сораулар иде... Башта: «Сезнең өчен җирдә иң кирәкле, иң кадерлесе нәрсә?» — диделәр. Беренче булып мин җавап бирдем. «Безнең өчен иң кадерле нәрсә — конфет», — дидем. Ә башкалар кайсысы... «тынычлык» ди, кайсы «әни» ди, кайсылары «кояш», «мәктәп» диләр. Хәтта бер конфет өчен үлә язып торган Мәлик тә, мине яманлап: «Тәмлетамак та инде син, Белми», — дип торган була.

Әнисе аны сөйләүдән бүлдерде:

— Ә икенче сорау ничегрәк иде?

— Икенчесеме? «Хезмәт кешесен кыерсытучы, хурлаучылар кемнәр алар?» — диделәр. Мин озак уйлап тормадым, «Мәлик» дидем. Чөнки ул «тәмлетамак» дип, әле генә мине кыерсытты бит. Дөресен әйттем, әни. Ә бүләк бирмәделәр...

— Дөрес әйттең микән соң, улым, — диде әнисе, — тагын бер кат уйлап кара әле...

Сез дә уйлагыз. Белмигә викторинада бүләк бирмичә дөрес эшләгәннәрме?



# Бабам хикәяте

Белми кош тоткандай елмаеп керде Гыйльми янына.

— Хәтерлисеңме, — диде ул, — теге вакыт авылга кайткач, Яңгыр малай буласым килә, дигән идем... Начальник буласы килә башлады бит әле. Әти дә: «Зур кеше чыгар безнең бу Белмидән», — ди. Начальник булу чынлап та шәп бит ул, ә? Күз алдыңа гына китер. Машина белән килеп алалар, китереп куялар.

— Үзең карыйсың инде анысын, — диде Гыйльми. — Сиңа аны өйрәтергә җыенмыйм. Әмма авылдагы яңгыр яудыручы бабам сөйләгән хикәятне тыңлау сиңа зарар итмәс иде.

...Борын-борын заманда Кырын тау дигән җирдә яшәгән, ди, йомраннар кабиләсе. Дансөяр исемле йомран кабилә башлыгы булган, ди. Кырын тау йомраннары аны шактый еллар буе үз башлыклары итеп сайлап килә икән. Электән килгән гадәт буенча, башлык итеп иң зирәк, иң көчле, иң үткен йомран сайланырга тиеш булган. Әмма соңгы вакытта бу таләп бозыла килгән. Сайлаулар җитә башладымы, Куштан йомран, Койрык йомран һәм Бөкре йомран моның янына киләләр дә: «Йомраннар кабиләсенең теләге аксакал итеп сезне калдыруда», — диләр. Ә Дансөяргә шул гына кирәк. Алай да бер уй борчый башлый моның күңелен. Аксакал итеп сайладылар сайлавын, тик гаепләнеп китәргә туры килмәгәе. Гаеплене, ни генә булмасын, йомраннар хөкем итә. Аны үз иленнән куалар, андый башлык ялгызлыкта һәлак була.

Менә шушы мәгънәсез гадәтне ничек юкка чыгарырга? Монысын да ахырга кадәр җиткерә алса, гомер буе курыкмыйча кабилә белән идарә итәр иде. Сер түгел, күзенең үткенлеге юк, көче, сәләте дә мактанырлык түгел, зирәклек тә чамалы. Шулай булгач, хата кылынмас дип кем әйтә алыр?

— Хаталанудан саклый күр, — дип көрсенеп куйды Дансөяр.

Шунда кинәт кенә мичкәдән чыккан күк тавыш яңгырады:

— Үзең сакланмасаң, кем сакласын сине, әй Дансөяр?!

Баш йомран урыныннан сикереп торды да алгы бүлмәне карады, сарайны, аннары печән асларын актарып бетерде. Бер җирдә беркем юк иде.

— Әллә саташуым инде. — Дансөяр ирексездән колак яфракларын тотып карады. — Юк, игелеккә түгелдер бу. Иртәгә үк кабилә йомраннарын җыеп алырга да аксакал булудан баш тартырга кирәктер, бәлки...

Баш йомран уйга калды. Шушындый зур кабиләне кемгәдер калдырыргамы? Карты-яшенең хөрмәтеннән мәхрүм булыргамы? Бөтен нәрсә минем кулда бит хәзер. Бер сызгырсам, йомраннар ояларына кереп посалар, икенче сызгырсам, ялт итеп ояларыннан килеп чыгалар, азык эзләргә керешәләр, мине туйдыралар...

Мондый дан, мондый хөрмәттән ничек баш тартасың? Аксакал башың белән кемгәдер буйсынырга, кемнеңдер әмерен үтәргәме? Юк, булмый. Иң яхшысы, кабиләне саклау эшен йомраннарның үзләренә тапшырырга гына кирәк...

Шундый уйлардан башы катып, карт йомранның тәмам йокысы качты. Инде таң да беленеп килә иде. Йомраннарны табигать кочагына ризык хәстәрләргә чакырырга да вакыт җитте.

Кояшның тәүге нурлары сибелүгә, Дансөяр оясыннан башын тыгып сызгырып җибәрде. Йомраннар берәмберәм, ояларын калдырып, Кырын тау битенә сибелделәр.

Аксакал бүген әле үзе сакта. Ә иртәгә теге уен үткәрә алса, эше җиңеләячәк. Үзең кабилә башлыгы да һәм бернәрсәгә җавап та бирәсе булмаячак...

Чү! Тау итәгенә елышып кемдер шуыша түгелме? Аксакал күзләрен бер ачып, бер йомып күзәтергә кереште.



Начар күрәләр шул күзләр. Их, үткенрәк булса алар!.. Шулай да, ятып калганчы атып кал, дигән борынгылар. Ничек кенә булмасын, кача-поса килгән җанвар йомраннар дусты булмас.

Аксакал, тәвәккәлләп, биегрәк урынга басты да, Кырын тауны яңгыратып, өзек-өзек итеп сызгырып җибәрде. Бу аның: «Йомраннар, сакланыгыз, дошман бар», — дигән сүзе иде. «Ә» дигәнче барлык йомраннар ояларына кереп посты. Аксакал үз оясына иң соңыннан гына керде. Дөресрәге, керде дә, муенын сузып, теге җанварны күзәтмәкче булды. Тик күзләре берни дә аера алмады. Җанвар дигәне төлке иде. Әнә ничек хәйләкәр кылана ул. Йомраннар кереп качкач, ул да борылып киткән булып кыланды да чокырга кереп ятты. Ә үзе сиздерми генә Кырын тауны күзәтә башлады, йомраннар нишләр икән, янәсе.

Төлкене күздән югалткач, Дансөяр, оясыннан чыгып, тагын сызгырып җибәрде. Бу — аксакалның, янәсе, куркыныч үтүен белдерүе иде. Йомраннар шунда ук тагын Кырын тауга сибелделәр. Шул чакта Кырын тау өстендә кара нокта пәйда булды. Тилгән... Ул әле төшкәндәй, әле күтәрелгәндәй итеп биектә тирбәлеп тора. Аксакал аннан күзен алмый.

Тик ялгышты шул Аксакал. Тилгәнне күзәтеп, җир өстен күзеннән ычкындырды. Бу арада чокырга поскан төлке Аксакалның артыннан ялт итеп килеп чыкты да бер сикерүдә яшь кенә бер йомранны эләктереп тә алды. Чыелдау тавышыннан Аксакал айнып китте, сызгырмакчы булды. Ләкин тавышы чыкмады, чыкса да соң иде инде.

— Хыянәт, — диделәр йомраннар, — хыянәт!

Аксакал хәбәр салмады.

Аннары, барысы бергә җыелышып, Аксакалга ташландылар. Ә күктә тилгән тирбәлә. Ул якынайганнан-якыная... Аксакал, куркыныч килүен күреп, әче итеп сыз-

гырып җибәрде. Ләкин аны инде бер генә йомран да тыңламый иде. Үзен типкәләп, талый-талый илләреннән куып җибәрделәр.

Качар урынсыз, оясыз, ялгыз башы бушлыкта калды Дансөяр. Тилгән исә аны ачык җирдә бик тиз күреп алды һәм өстенә уктай атылды. Соңгы мәртәбә йөрәк өзгеч әче итеп сызгырды Дансөяр. Ләкин инде аны тыңлаучы да, ишетүче дә юк иде...

— Ничек, ошадымы бабам хикәяте? — диде Гыйльми.

Борыны салынган Белми исә:

— Ә минем күзләрем, беләсең килсә, бик зирәк,— диде.



## «Янгыр бабай»

Җәйге каникуллар җиткәч, Гыйльмине дәү этисе кунакка алырга килде. Китәргә җыенгач, Гыйльми дәү этисен читкәрәк чакырды да колагына гына:

— Мине озатырга килгән менә бу малайның исеме — Белми. Аны да үзебез белән алыйкмы, дәү эти? — дип пышылдады.

— Алыйк соң, улым, бергә-бергә күңелле булыр. Икәүләп болында йөрерсез, Ыкта балык тотарсыз...

Гыйльминең дәү этисен элегрәк авылда «Тимер бабай» дип йөртәләр иде. Моның үзенә күрә сере дә бар. Бу бабай башта тимерче булган. Ык буенда колхоз төзелгәч, шунда ул беренче булып тимер бөккән, аннары беренче тракторларны йөрткән. Шуннан аңа «Тимер» дигән кушамат тагылган...

Ә менә бүген алар авыл урамына килеп керүгә, малай-шалай, беравыздан:

— Яңгыр бабай кайтты! Яңгыр бабай кайтты! Исәнме, Яңгыр бабай! — дип сәламли башладылар.

Берни белми торган Белми дә, күпне белә торган Гыйльми дә аптырашта калдылар: нигә Яңгыр бабай булсын ди ул?

Әле узган килгәндә генә Тимер бабай иде бит дип уйлады Гыйльми күңеленнән. Ләкин сорарга батырчылык итмәде.

Юлдан соң өйгә кереп тамак ялгап алдылар да, бабай аларны болынга алып төшеп китте.

Их, Ык буенда шундый күңелле! Төрле-төрле кошлар сайрый. Чәчәктән чәчәккә кунып күбәләкләр оча, су өстендә балыклар уйный. Алар, әллә юри инде, үзләре артыннан тәңкә-тәңкә түгәрәкләр калдырып, малайларның күзен кызыктыралар.

— Хәзер, оланнар, хәзер, — ди Гыйльминең дәү этисе, малайларның балык тотарга ымсынуын аңлап. — Яңгыр

гына яудыра башлыйм да сезгә кармаклар җайлап бирермен.

— Син яңгыр яудыра беләсеңмени, бабай? — диде Белми, аптырап. Аннары өстәп куйды: — Түлке яңгыр яуганда чыланырбыз бит, балык та капмас...

Бабай исә:

— Мин сезнең өскә яудырмыйм, курыкмагыз, — дип сөйләнә-сөйләнә, ниндидер бер тимергә үрелгән иде, болында, көтүлекләрдә, яшелчә бакчасы өстендә чыннан да коеп яңгыр ява башлады. Болын өстендә бар төсләрне үзенә җыйган салават күпере балкыды.

Моны күреп малайлар таң калды. Чынлап та, моңарчы кем яңгыр яудыра алган? Менә нигә малайлар хәзер минем дәү әтиемне «Яңгыр бабай» дип сәламлиләр икән...

Гыйльми умартачы булырга хыяллана иде. Ә дәү әтисенең хикмәтен күргәч:

— Яңгыр малай буласым килә, — дип әйтүен сизми дә калды.

Дәү әтисе аның аркасыннан сөйде.

— Булырсың, улым, булырсың, күп белергә теләгән кеше барын да булдыра ул. Менә мин дә инде олыгаеп киләм. Тагын бер ел яудырам да яңгыр яудыручы серле таягымны яшьләргә тапшырырга уйлыйм. Сез болыннарга гына түгел, кырлардагы арышларга, бодайларга да яңгыр яудырырсыз әле...

— Мине дә өйрәтерсеңме, дәү әтием? — диде Гыйльми.

— Мине дә, — диде Белми. — Минем дә Яңгыр малай буласым килә!..



## Җирәнкәй

Ул елны август гаҗәп бөркү килде. Туктаусыз эчәсе килеп тора. Гыйльми белән пешекче апа тракторчыларны сыйлый да комбайнчылар янына китә.

Ә юл өстендә генә Әреш чишмәсе. Суы да суы инде. Үзе салкын, үзе көмеш кебек саф. Эчеп туймаслык. Көмеш судан Җирәнкәйгә дә өлеш чыгара Гыйльми. Тегесе чиләкне төбенә кадәр ялт итә дә күзләрен тутырып аңа карый, әйтерсең: «Булып җитмәде бу, азрак өстә инде»,— ди.

Гомумән, алар бер-берсен ярты сүздән аңларга өйрәнделәр. Гыйльми шунда ук тагын чишмәгә йөгерә. Җирәнкәй исә йотлыгып көтеп тора. Икенче чиләкне беркайчан да эчеп бетерми ул. Яртысына кадәр суыра да, чиләктән аерылып, дустына башын кагып куя:

— Рәхмәт, абзыкаем. Сулы Чокырга җиткәнче түзәргә була хәзер...

Җирәнкәйгә шундый ияләште Гыйльми. Һәр елны мәктәптә укулар тәмамлануын, каникуллар башлануын түземсезлек белән көтеп ала ул. Авылга кайту белән үк, җәйләүгә — Җирәнкәй янына йөгерә. Аның белән колхозда печән җыеша, чүмәлә тарттыра, витаминлы яшел азык әзерләшә. Аннары урак өсте дә җитә. Быел алар бергәләп өченче уңышны җыюда булышалар. Шул вакыт эчендә дә ниләр генә булмады! Беркөнне шулай пешекче апаны ашыгыч рәвештә машина белән җәйләүгә алып киттеләр. Берничә сәгатьсез бушамас, диделәр. Аның кайтуын көткән арада, Гыйльми, тезгенен бушата төшеп, Җирәнкәйне чирәмлеккә җибәрде дә үзе якындагы салам чүмәләсе төбенә барып ятты. Тәмле әбәттән соң изрәп йоклап киткән. Шулай күпме яткан булыр иде, Җирәнкәйнең кырны яңгыратып ничектер хәвефле кешнәвенә уянып китте. Үзе кешни, үзе Гыйльмигә таба юырта. Нәрсә булган дисә, янәшәдәге салам чүмәләсе дөрләп янып ята икән. Кемдер тәмәке төпчеге ташлап калдырган булса кирәк. Ут телләре менә-



менә камыл буйлап урылмаган мәйданга күчәргә тора...

Җирән бия Гыйльми янына килеп туктады да, бер-бер хәл кылыйк инде дигәндәй, дустының маңгаеннан, муеныннан сөзгән кебек итеп ашыктыра башлады. Гыйльми дә озак көттермәде. Арба төбенә җәйгән брезентны тартып алды да урылмаган бодай басуына таба шуышкан ут телләренә каплады. Өстенә менеп таптады да брезентны алып тагын икенче урынга каплады, тагын, тагын... Ә Җирәнкәй, тояклары белән камылны куптарып, ут өстенә балчык сибәргә кереште. Ә үзенең күзләре, карашы... Икмәкнең кадерен белми Җирәнкәй дип кем әйтә алыр? Озакламый ярдәмгә пешекче апалары да килеп җитте. Иртәгесен исә колхоз идарәсе Гыйльмигә китаплар, ә Җирәнкәйгә чуклы шлея бүләк итте.

...Урак инде төгәлләнеп килә иде. Әмма укулар башланырга ун көн чамасы вакыт бар әле. Гыйльми бер генә көнгә өенә кайтып килергә булды. Авылга икенче көнне кичкә таба гына әйләнеп килде ул. Авыл балалары аны моңсу каршы алды. «Җирәнкәй харап булды инә, — диде берсе, еларга җитешеп. — Җан бирә алмый интегә... Яраткан кешесен көтә ул, шуңа җан бирә алмый, ди».

Бу сүзләрне ишетүгә, Гыйльминең күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп киткәндәй булды, ни эшләргә белми аптырап калды:

— Җирәнкәй кайда?

— Әреш чишмәсе буенда, — диде малай. — Синең урынга калган теге Белми көне буе су эчертмәгән месренгә... Сусавын басарга теләпме, Җирәнкәй бертуктаусыз бодай ашаган. Ә кичен су эчү белән егылган инә...

Гыйльми килгәндә, Җирәнкәй әле исән иде. Дустын күргәч, ул көч-хәл белән булса да башын күтәрде, аңа таба ымсынды. Күзләре моңсу, Гыйльми аларда мәңгегә аерылышу хәсрәте тойды. Ул күзләр: «Сине генә көттем, хәлем бик авыр», — ди кебек иде. Гыйльми, ул күзләрне үбә-үбә, Җирәнкәйнең муенына сарылды...

# Читекле Кәтүк

Читекле мәчене күргәч, малайлар кызыксынып туктап калдылар. Мәче исә читекле аякларын алгарак сузып нәрсәдер сагалый иде.

— Кем мәчесе булыр икән бу?

— Кемнеке булсын, гыйлем иясе Гыйльминеке инде,— диде Белми, малайларны көлдерергә теләп.

Тик беркем дә көлмәде.

Шул арада Гыйльми дача өеннән чыкты да мәчене чакырып алды:

— Кәтүк, Кәтүк, өйгә кер...

Кәтүк белән алар бер-берсен әле шушы кышны гына табыштылар... Ул көнне Гыйльми дачага килсә, хәйран



калды. Бер генә әйбер дә үз урынында түгел иде. Киемсалым тузгып беткән, савыт-саба тәгәрәшкән. Иң кызганычы — бүрек: карар җире калмаган иде яраткан бүрегенең, бөтенләй теткәләнгән, бары тик йон кисәкләре генә тузгып ята. Кем үчләнгән бу кадәр бүреккә? Кем аның тиресен ашап, йонын туздыра барган?.. Күседер, мөгаен...

Ул көнне бик күңеле төшеп кайтып китте Гыйльми бакчадан. Барган саен шундый хәл булса, куйган әйберең урынында тормаса, нәрсә эшләрсең?..

Гыйльминең кайгысын уртаклашкандай, моңсу гына мәче тавышы ишетелде:

— Мияу! Мияу! Мине ал, Гыйльми! Мин һәрвакыт уяу!

Котельныйдан ак дисәң ак түгел, кара дисәң кара түгел бер мәче баласы чыгып килә иде. Күмер арасында аунап яткан-яткан да, кемгә дә булса файда китерергәме, елышыргамы дип чыгып килүе иде, күрәсең. Аның тавышыннан Гыйльми айнып киткәндәй булды.

Карап торуга юаш кына булып күренсә дә, бик зирәк мәче булып чыкты ул. Гыйльми аны кулына да алырга өлгермәде, сырпалана, кулларын ялый башлады. Монысы инде, гомерлеккә дус булыйк, дигәне иде, ахрысы.

Өенә алып кайткач, Гыйльми аңа Кәтүк дип исем кушты, сабын белән әйбәтләп юды, киптерде. Мәченең йоннары кабарып, матурланып китте. Гыйльми ни эшләсә, мәче дә шуны кабатлый иде. Иртән бер үк вакытта торалар. Гыйльми зарядка ясый, Кәтүк тә калышмый, сырпаланган була, сузылып ята, аннары сикереп тора да битен юа башлый...

Шулай бер атна үтеп тә китте. Якшәмбедә алар бакчага икәүләп киттеләр. Дача өендә тагын бөтен әйбернең асты өскә килгән иде. Кәтүк йомылып кына почмакка сөяп куелган картон артына кереп китте. Күп тә үтмәде, ниндидер әче итеп чинаган тавыш ишетелде.

Тычкан дисәң тычкан түгел, мәче тавышына да охшамаган. Үзе дә аңышмастан, Гыйльми тавыш килгән якка ташланды. Картоннарны читкә этәреп куйган иде, хәйран калды...

Кәтүк бер озын койрыкны эләктергән дә мырлап ята. Ә күсе исә ярыкка кысылган, алга да, артка да китә алмый. Алга китәр иде, койрык авырта, артка китәр иде, борылыр җир юк — Кәтүк саклап тора...

Бүрек өчен шулай үч алды аннан Кәтүк. Атна саен тырышып хезмәт итте ул Гыйльмигә. Өйдә дә, өй тирәсендә дә тәртип урнаштыргач, күрше дачаларга йөри башлады.

Февраль ахырлары иде. Чыгып киткәч, Кәтүк бик озак кайтмады. Гыйльми бәрәңге пешерергә, чәй кайнатырга да өлгерде. Көтеп-көтеп тә кайтмагач, мәчене эзләргә үзе чыгып китте. Төштән соң суытып җибәргән иде. Әче җил бит очларын өтеп ала...

— Кәтүк, Кәтүк, кайда син? — Гыйльми, дачадан дачага кереп, эзләвен дәвам итте. Бервакыт ул аз гына ыңгырашкан сыман тавыш ишетте. Яхшылап караса: Кәтүк. Кемнеңдер тычканнарга дип куеп калдырган капкынына эләккән икән. Газапланган, тәмам хәлдән тайган, месккенкәй. Җитмәсә, тәпиен дә өшеткән.

Шуннан соң Гыйльми аңа калдык тире кисәкләреннән читек тегеп кигезде. Әгәр дә Идел буендагы дачаларда читекле мәче күрсәгез, аңа хөрмәт белән баш иегез. Ул Гыйльминең читекле Кәтүге, дачаларны тычканнардан, күселәрдән саклаучы мәче булыр.



# Мукжан һәм Иске читән

Мәктәптән кайтышлый Белми Гыйльмине куып җитте:

— Beләсеңме, мин нинди фикергә килдем. Безнең дуслык бетеп бара бит. Әллә түгәрәкликме дим.

— Нигә болай бик кызып киттең әле?

— Нигә дип соң... Син яхшы укыйсың, мин чак-чак «өчле»гә тартып барам... Бу — бер. Икенчедән, сине һәрчак мактыйлар, ә миңа күп вакыт таякның юан башы эләгә. Аннары, синең дуслар болай да күп...

— Ялгышасың син, Белми... Дусларым күп булса да, син алар арасында иң якыны... Җирнең юлдашы — Ай кебек син миңа...

— Мүклеккә читән кебек түгелме тагын? Кемгәдер шулай дип тә сөйләгәнсең бит әле... Тапкан сөйләр сүз... Иске читән белән мүк арасында нинди уртаклык булсын ди.

— Ничек кенә әле, Белми дус... Тыңлыйсыңмы, сөйлим.

Белминең артка чигенәсе килмәсә дә, тыңларга теләге бар иде.

— Әйдә, сөйләп кара...

Гыйльми кулын Белминең иңенә куйды да:

— Бу хәл авылда була, — диде. — Яз яңгырлы килә ул елны. Иске читән күләгәсе төшкән урын ямь-яшел мүк белән каплана. Мүккә тагын нәрсә кирәк, рәхәтләнеп үрчисе, шулай яшисе иде югыйсә... Тик Мүкҗан мондый яшәүдән канәгать булмый. Болытлар арасыннан кояш күренүгә, ул тирә-юньгә ишетелерлек итеп оран сала:

— Кем куйган бу читәнне? Аның аркасында зәңгәр күкне, кояшны күргән юк. Җылы җилдә рәхәтләнеп ләззәтләнә алмыйбыз. Яшәүмени бу? Үткәр инде гомереңне иске читән артында. Көчлерәк давыл чыгып кубарып та ташламый, ичмасам, шул беткән нәрсәне...

Мүкҗанның сүзләрен ишетеп торган диярсең, бакча хуҗасы үтешли Иске читән янында туктала. Аннары ул, уйга бирелеп, читән казыгына таяна. Түзми казык, сынып ук чыга.

— Бакчабызның читәне беткән икән, алыштырырга кирәк, —ди агай. — Читән урынына тимерчыбык кына сузсам да ярап торыр.

Мүкҗан исә, читәннең җимерек урыныннан кояш көлгәч, сөенеп бетә алмый: «Безгә хәзер кояш көн дә елмаеп карар, рәхәтләнеп җылы җилдә иркәләнербез»,— ди ул.

Иртәгесен хуҗа кеше эшкә керешә. Иске читәнне ул бер сәгать эчендә сүтеп ташлый: урыны ялт итеп кала.

Төш вакытында көн гаҗәп эсселәнә. Кояш кыздырып-мы-кыздыра. Читәнне алуга, мүклек сәлперәеп төшә. Мүкҗанның хәле чынлап та шәптән булмый. Тыны бетә, тәне сусый. Аннары ул бөтенләй кибә, куырыла башлый. Үлем белән тарткалашкан арада, өзгәләнеп ярдәм сорый:

— Читәнне кем алды?.. Кире куегыз!.. Читәнкәйне!..

— Шуннан... шуннан ни булган? — диде Белми.

— Шуннанмы? Шуннан ни булсын. Инде соң булган. Эш үткәч, терсәк якын булса да, тешләп булмый икән, Белми дус.



## «Батыр» помидор

Туфрак өлгерә төшүгә, Гыйльми, түтәл ясап, редис чәчте. Редис белән бергә бер помидор орлыгы да эләккән иде түтәлгә. Берничә көн үтүгә, редис тигез рәт булып тишелеп тә чыкты. Помидорның да алардан калышасы килми иде. Менә ул акрын гына өстендәге балчыкны этәрә башлады:

— Ни эшлисең, тилердең мәллә? — диделәр аңа парниктагы помидор үсентеләре. — Әле иртән генә транзистор тотып Белми үтеп киткән иде. Һава торышын әйттеләр: төнлә кырау төшәчәк.

Парниктагы помидорлар ялгышмады. Кичкә таба бик нык салкынайтып җибәрде, Гыйльми парниктагы помидорларны әйбәтләп каплап куйды. Әмма редис арасында тишелеп чыккан помидорны ул күрмәде. Помидорның әле генә яралган яфраклары суыкта дер-дер калтырый башлады. Редислар бик кызганды үзен. Һәркайсы аны суыктан сакларга, капларга тырышты.

— Түз, түз, яфрагым, — диде помидор, — тиздән кояш чыгар, таң атар, җылытып җибәрер...

Түзде помидор. Азрак салкын тиде тиюен, тик барыбер исән калды.

Редис дуслары белән бергә үскәндә рәхәт иде помидорга. Әмма май ахырында инде редис өлгерде. Гыйльми аны көн дә сайлап кына җыеп алып керә. Түтәлдәге редислар сирәгәеп калгач кына, Гыйльми помидорны күреп алды:

— Ничек исән калдың син, суыкларга ничек түздең? — диде ул аңа. Аннары төбен йомшартты, сыен бирде, су бөркеде. Түтәлдә ялгыз гына калган помидор күзгә күренеп үсеп китте.

Ул елны яз бик кырыс килде. Иртән кояш көлсә, кичен салкын җил исеп куя. Менә бүген тагын да салкынайтып җибәрде.

— Тыңламадың безнең сүзне, — диделәр пыяла аша парниктагы үсентеләр помидорга. — Менә хәзер кәкрәясең инде. Янәшәңдә редислар да юк җылытырга...

— Кайгырмагыз, — диде ялгыз помидор. — Мондый гына салкыннарга түзәргә өйрәндек инде...

Чыдам помидор чынлап та бирешмәде, яшь яфраклар ныгыды, чыныкты һәм суыклардан курыкмый башлады.

Менә май да үтте, җылы җилләре белән июнь килде. Гыйльми парниктагы үсентеләрне бакчага күчереп утыртты. Озакламый помидорлар шау чәчәккә күмелделәр.

Әмма июньдә дә сирәк кенә булса да салкыннар булгалый икән шул. Төньяктан кинәт кенә салкын җил исте, төнлә уйсу урыннар юка гына ак бәс белән капланды. Чыдам помидор моңа күнеккән иде инде. Тик менә парникта үскән помидорлар кичерә алмады бу суыкны. Кояш чыккач, һәммәсе сәлперәеп төштеләр.

Чыныккан помидор исә көзен Гыйльмигә матур-матур җимешләрен бүләк итте. Гыйльми кызыл помидорларны орлыкка булыр дип башта тәрәзә төбендә тотты. Берничә көннән алар бөтенләй өлгереп җиттеләр. Гыйльми, җимешен ачып, эчендәге вак кына орлыкларын алды да юып киптерде.

Әнә никадәр орлык... Чыдам помидор орлыклары... Гыйльми аларны җыеп пакетка салды һәм тышына «Батыр» дип язып куйды.

Шул елдан бирле «Батыр»ны Гыйльми генә түгел, тагын бик күп бакчачылар үстерә.



## Белми белән Сукыр тычкан

Белми җиләк төпләрен йомшартып йөргәндә, Сукыр тычкан эзенә төште. Китте бу казып эз буйлап. Эз борыла-сарыла җир астыннан бара да бара. Белми каян казый башлаган булса, шунда әйләнеп кайтты, бөтен бакчаны казып бетерде, ә Сукыр тычканны таба алмады.

— Белми, — диде шулчак җир астыннан сәер генә бер тавыш. — Ник эзлисең мине? Нигә кирәк булдым әле мин сиңа?

— Ә, Сукыр тычкан, саумы? Нигә дип гел җир астында казынасың? Чык якты дөньяга!

— Ни калган соң анда миңа? Якты дөньягызны да әйтер идем инде...

— Нәрсә булган дөньяга?

— Нәрсә булган... Менә монда минем бабайның архивлары саклана. Укып-укып карыйм да хәйран калам. Бабайның язуынча, сезнең бакча артында Якты күл булган, анда парлашып аккошлар йөзгән...

Өсте мазут белән капланган саз ягына күз ташлады Белми.

— Синең эткәң нефтьче булгач, аккошлар мазутлы күлдән каракош булып очканнар. Шуннан соң анда бер генә кош та килмәгән. Килмәде дисәң хак булмас. Кайвакыт су эзләп казлар, үрдәкләр чумалар-чумалар да капкара булып килеп чыгалар. Ә син «якты дөнья» дисең, «чык» дисең...

Белми ни әйтергә дә белми аптырап калды. Ә Сукыр тычкан сүзен дәвам итте:

— Әнә тегендә, Якты күлдән өстәрәк, зифа каеннар үскән. Шул каенлыкта бик матур җиләкле алан да булган...

Белми, күзләрен уа-уа дигәндәй, каеннарны эзләде. Каеннар да, каенлыктагы алан да күренми иде.

— Яп-якты шул аланга бермәлне футуристлармы шун-

да, туристлармы килеп чыга. Тавышларына чыдый алмый бабам, башын авыруга сала. Ә аландагы каеннар теге җүнсезлар аркасында янып бетә, яп-якты алан карала. Аннары шәһәр чүбен китереп түгәләр, бар пычракны шунда өяләр. Боларда бит синең дә өлешең бар: син дә кеше ич...

Сукыр тычканның сүзләренә Белминең ачуы чыкты.

Аяк астында яткан ташны эләктерде дә тавыш килгән якка томырды. Аңа карап тавыш тынмады, Белминең алдында түгел, артында ишетелә башлады:

— Ә син: «Якты дөньяга чык», — дисең. Якты дөньяда булсам, синең ул ташыңнан бөтенләй дөнья куйган булыр идем. Көмеш сулы Агыйделләр турында сөйләрмен дигән идем, ярар инде. Дөресен әйткәнне яратмагач, миңа нәрсә: каралса да, ярылса да, үз дөньягыз... анда сез яшисе. Сукыр тычкан түгел бит сез — кешеләр...



# Кара тавык йомыркалары

Беркөнне әнисе Белмине базарга йомырка алырга җибәрде. Киткән чакта:

— Ишетсен колагың, карап ала күр, бозыгы-фәләне эләкмәсен, — диде.

Әле бер, әле икенче сатучы янына килде Белми, эреләрен генә сайлап алмакчы була, тик моны йомыркага якын җибәрмиләр.

Нәрсә эшләргә соң? Базарда инде кеше дә азаеп бара. Шулчак Белми бер читтәрәк басып торган сатучы кыз янына килде:

— Әй, чибәр кызый, минем әбием бик каты авырый. Аңа кара тавык йомыркасы гына ашарга кушалар... Миңа кара тавык йомыркаларын гына сайлап бир әле.

— Мин бит аера алмыйм аларны, булдыра алсаң, үзең сайлап ал, — ди кыз.

Белмигә дәрт кереп китте.

— Ник аермаска, аерам, — диде. Кызның кәрзинендәге иң эре йомыркаларны гына сайлап алды да акчасын түләп китеп тә барды.



# Аукцион

Белминең аукцион үткәреп карыйсы килде. Әмма моның нәрсә икәнлеген, ничегрәк үткәреләсен тәгаен белеп җиткерми иде. Аңа тагын Гыйльми ярдәмгә килде:

— Аукцион ул — нинди дә булса әйберне, ягъни товарны, сатулашу юлы белән аңа иң югары бәя биргән затка сатарга омтылу, — дип төшендереп бирде Гыйльми. — Ә син нәрсә сатмакчы буласың соң?

— Үзем укып чыккан китапларны.

— Алучы булырмы соң? Кая, карыйк әле, ниндирәк китаплар икән?

— Менә монысы Шәүкәт абый китабы, Җәүдәт Дәрзаман белән Фарсель Зыятдиновныкы да бар.

— Ярар, карап карарбыз... Алайса, без барлык малайларга да аукционның кайчан буласын, кайда үткәреләсен әйтеп чыгыйк.

Белми барлык таныш һәм таныш булмаган малайларга алдагы шимбәдә кичке сәгать өчтә аукцион буласын хәбәр итте.

Билгеләнгән вакытка мәктәп ишегалдына уннан артык малай җыелды. Белми исә өстәлгә сатылачак китапларын чыгарып куйды. Малайлар ул китаплар белән берәм-берәм танышып чыкты. Сатулашуны Гыйльми үзе алып барырга булды.

— Шәүкәт абыйның китабы сатыла,— диде ул.— Башлангыч бәясе — ун сум. Кем күбрәк бәя бирә, китап шуныкы була.

— Китап минеке була, — диде Үсәр. — Мин ун сум илле тиен түлим.

— Ун сум илле тиен — бер... Ун сум илле тиен — ике,— диде Гыйльми.

Шулчак Әхмәт, ашыгып:

— Үсәргә тәтеми торсын әле, мин унике сум бирәм, — дип кычкырды.

Гыйльми исә өстәлгә сугып санавын дәвам итте:

— Унике сум — бер... Унике сум — ике...

# Индексацияләү

— Исәнме, Фатыйма әби!

— Саумы, Гыйльми улым! Алланың рәхмәте дигән... Әле генә синең турыда уйлап утырган идем. Бик тә күрәсем килгән иде. Карасам, үзең килеп чыктың. Бер соравым бар иде сиңа. Безнең шул пенсия турында инде...

— Бик аз түлиләр шул, Фатыйма әби. Кая җитсен инде ул? Арттырмыйлар бит.

— Юк шул, улым, юк шул. Әнә беркөнне радиодан Зиастинов дигән кеше дә шул турыда сөйләде. Закон буенча пенсия һәр квартал саен индикчияләнергә тиеш, ди. Чияләнгәч нәрсә була соң инде ул? Үзе тагын, пенсия күтәрелеп торырга тиеш, ди. Индикчияләү нәрсәне аңлата соң ул, улым?

— Индексацияләүме?

— Әйе, әйе.

— Бу — чит ил сүзе, Фатыйма әби. Аңлашылмаса да гаҗәп түгел. Индекс ул күрсәткеч дигәнне аңлата.

— Алайса, татарча — күрсәткечләр була инде.

— Бераз шуңа да охшаш инде ул. Әйтик, II кварталда инфляция I квартал белән чагыштырганда 1,3 тапкыр үсте ди. Бу инфляциянең үсеш күрсәткече була. Аңлашыламы?

— Әйе, әйе. Димәк, бәяләр уртача шулкадәр күтәрелгән, акча шулкадәр очсызланган дигән сүз.

— Нәкъ шулай, Фатыйма әби. Сез икътисадны үзегез дә хәйран беләсез икән. Менә шул... акча очсызлангач, сезнең пенсиянең дә сатып алу көче кими дигән сүз.

— Шулай шул. Элегрәк пенсиямнән азрак колбаса алырлык та кала иде. Ә хәзер эремчеккә дә җитми. Ярый әле сөт белән икмәккә җитә.

— Пенсияне индексацияләмәсәләр, анысына да җитми башлаячак ул, Фатыйма әби. Әйтик, инфляция 1,2 тапкыр арткан икән, пенсияне дә шулкадәр арттыру зарур.

— Монысы аңлашылды. Шушы буламыни инде ул индиксияләү дигәннәре?

— Шул була, Фатыйма әби. Пенсия күләме инфляциянең үсеш темпы белән тәңгәлләштерелергә тиеш. Бу законда каралган, тик үтәлми генә.

— Зиастинов та шулай дигән иде шул. Һәй, бу Рәсәйдә законны санлаучы бармыни ул? Димәк, закон буенча, минем пенсия бу кварталда 1,3 тапкыр артырга тиеш.

— Нәкъ шулай. Шул чакта гына яшәү шартлары начарланмаячак. Пенсия генә түгел, халыкның башка керемнәре дә, әйтик, хезмәт хакы, стипендия дә индексацияләнергә тиеш. Ләкин болары да эшләнми. Соңгы елда инфляция энә күпмегә үсте, ә хезмәт хакы үзгәрмәде, шул ук калды. Димәк, халык шулкадәр үк хәерчеләнде дигән сүз.

— Моның бер чиге булыр микән соң, улым?

— Әгәр дә чик куючы табылса... Чиновникларга нәрсә аларга? Рәхәттә яшиләр. Монда халык үз сүзен әйтергә тиеш.

— Яшь кенә булсаң да, белеп сөйлисең. Рәхмәт, улым, рәхмәт. Тагын килермен әле мин синең янга.

— Рәхим ит, Фатыйма әби. Мин бик шат булырмын.

# Фермер балык

Аланда йөреп, зәңгәр һәм сары мәтрүшкәләр, шифалы ромашкалар җыеп арыгач, Белми елга буена ял итәргә утырды. Тын гына ага елга, аның өстендә ялгыз бер акчарлак балык күзли. Аны күрүгә, балыклар, дәррәү килеп, тирәнгәрәк качалар. Тик бер ташбаш кына уйлап та бирми, акчарлактан гел дә курыкмый. Белми, моның серен белергә теләп, Гыйльмине чакырды.

— Нәрсә булды тагын? — диде Гыйльми, куаклар арасыннан чыга-чыга.

— Күр әле менә бу ташбашны, акчарлактан куркып та карамый. Әллә сукыр микән ул?

— Сукыр түгел, фермер балык ул. Акчарлакның якын танышы, беләсең килсә.

— Кит әле моннан, юкны сөйләмә, каян килеп таныш булсын ди ул акчарлакка?

Гыйльми, бик җитди кыяфәткә кереп, Белмигә текәлеп карады да:

— Ышанмыйсыңмыни?— диде. — Әнә кара, акчарлак бөтенләй аның янына ук килде, ә ташбаш койрыгын гына селкетте. Бу аның: «Рәхмәт, акчарлагым, коткаруың өчен мең рәхмәт!» — диюе. Аның бөтен сере дә менә шунда, Белми.

— Нинди сер ул, Гыйльми?

— Язлар җитеп, елгалар тулып аккан матур бер таңда Ташбаш, бүтән балыклардан аерылып, ялгызы тыныч кына фермер булып яшәмәкче булган. «Туйдым бу балык колхозыннан, кая карама балык, хәтта иркенләп йөзәргә дә ирек бирмиләр», — дип сөйләнә-сөйләнә, ялгызы гына бер яңа култыкка кереп киткән. Йөзгән дә йөзгән бу һәм моңарчы бер балык та «аяк басмаган» урынга килеп чыккан. «Менә монда яшәсәң дә ярый, беркем комачауламый», — дип уйлаган үзе һәм күп итеп уылдык сипкән. Шулай итеп, көн арты — көн, атна арты атна үткән. Ташулар тынгач, су да китә башлаган. Таш-

баш култык суында зур елгадан бүленеп үк калган. Шуннан моның күле ай кибәсен көн кибә икән. Ахырда бөтенләй саеккан. Ташбашка чумып уйнар урын беткән, тыны кысыла башлаган моның, йөзүләре читенләшкән, уылдык кипкән. Нәрсә бу? Хәзер ни эшләргә? Киңәшер, сорашыр иде, күлендә башка бер җан иясе дә юк. Ташбаш, тәмам акылдан язар хәлгә җитеп: «Үз халкың, үз балыкларың белән яшәүгә ни җитә?» — дип кайгырган, уфтанган.

Ә иртәгесен кояш тагын да ныграк кыздыра башлаган. Ташбашның күлендә күп булса бер уч су калган. Ә кичкә анысы да бетәчәк. Нәрсә эшләргә? Аның күлендә генә түгел, тирә-юньдә — җирдә дә, күктә дә — бер җан иясе күренми. Ташбаш барысына кул селтәп җан бирергә җыенганда, аның «күле» өстенә ялгышыпмы, газапланып яткан бу балыкны күрепме, акчарлак килеп чыккан.

Ташбаш исә, калган бар көчен җыеп: «Акчарлагым, кадерлем, коткар мине!» — дип, бер уч судан өскә сикергән. Шунда моны акчарлак эләктереп алган да очып киткән. Туган елгасы өстеннән үткәндә, Ташбаш: «Рәхмәт, акчарлагым, мең яшә!» — дигән. Акчарлак исә: «Нәрсә кирәк сиңа?» — дип авызын ачкан икән, ташбаш елгага төшеп тә чумган...

Гыйльми сөйләп бетерде дә:

— Әнә игътибар беләнрәк кара әле син, — диде Белмигә. — Ташбашның сыртында яра эзен күрәсеңме? Акчарлак яралаган аны. Әмма, яраласа да, туган елгасы, үз балыклары белән кавыштырган өчен һәрчак койрыгын селтәп рәхмәт әйтә ул акчарлакка.



# Эчтәлек

## Һәркемнең үз һөнәре


Бип-бип ........................... 4
Карга белән Шөпшә .......... 5
Сыерчыклар һәм Чык-Чыруйк ........................... 6
Тапкыр Гөләп .................. 9
Һәркемнең үз һөнәре ......... 11
Рәхмәт, кошкайлар! ........... 13
Минем әни ....................... 14
Җаен таптык .................... 17
Бигрәк тәмле бәрәңге ........ 18
Йокы качкач... ................ 20


## Гыйльми маҗаралары


Белемле — меңне егар ....... 22
Белми дисәң дә Белми ....... 26
Туган көнең белән, Гыйльми ............................... 29
Сөйләшә белүче кырмыска .................................. 32
Баллы кар ....................... 34
Йомышың төшкәч ............ 37
Гөблә ширбәте һәм кырмыска ................................ 40
Урман имәнсез калмагае ... 42
Күзлекне кем урлаган? ...... 44
Викторинадан соң ............. 46
Бабам хикәяте .................. 47
«Яңгыр бабай» .................. 52
Җирәнкәй ......................... 54
Читекле Кәтүк .................. 57
Мүкҗан һәм Иске читән ... 60
«Батыр» помидор ............. 62
Белми белән сукыр тычкан 64
Кара тавык йомыркалары .. 66
Аукцион .......................... 67
Индексацияләү ................. 68
Фермер балык .................. 70



Литературно-художественное издание
Для детей младшего школьного возраста

*Зиятдинов Фарсель Сахапович*

**КАТУШКА С ИЧИГАМИ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2010
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма
Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

*Зыятдинов Фарсель Сахап улы*

**ЧИТЕКЛЕ КӘТҮК**

Мөхәррире *А.М.Җамалиев*. Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*. Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*. Корректоры *Р.Н.Шакирова*. Оригинал-макеттан басарга кул куелды 19.12.2008. Форматы 70 ´ 100 1/16. Шартлы басма табагы 5,85. Тиражы 1500 д. Заказ Т-1006. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru. Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.